**Казан шәһәре Идел буе районы**
**247 нче мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

Нурфия Халикова

# “Һәр бәйрәмдә бар хикмәт!”

**Казан-2020**

**Кереш**

Балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүдә музыкаль кичәләр, бәйрәм иртәләре оештыру - зур һәм әһәмиятле урын алып тора.

Балаларга музыкаль белем бирү – музыка җитәкчесенең төп эше. Ләкин бу чаралар гади күңел ачу гына түгел, ә әти-әниләр каршысында сынау тоту, музыка җитәкчесенең, тәрбияченең, балаларның эшенә йомгак ясау булып та тора. Әти-әниләр, күп вакыт, шушы ачык чаралар вакытында балалар бакчасы тормышы эшенең ни дәрәҗәдә катлаулы да, җаваплы да икәнен күрәләр. Бәйрәм иртәләрендә балаларның белеме, үз-үзләрен тота белүләре, сөйләме, сәләтләре, җаваплылыклары, җитез булулары, кыюлыклары, актив булулары күренә. Ә бит болар барысы да музыка җитәкчесе, тәрбияче, тәрбияче ярдәмчеләренең бер юнәлештә, максатчан, эзлекле, даими тырыш хезмәт нәтиҗәсе. Мондый уңышларга бары тик бердәм рәвештә аңлашып, ярдәмләшеп эшләгәндә генә ирешергә була.

Бәйрәм кичәләрен планлаштырганда ук бергәлек кирәк: нинди җыр, ниди биюләр, уеннар, сюрприз моментлары, нинди герой-персонажлар кертергә кирәклеген; нинди киемнәр, маскалар әзерләргә икәнен сөйләшеп, кайсы хезмәткәр нәрсә өчен җаваплы булуын билгеләү мөһим. Бу очракта балалар бакчасында һәркем оештыру эшенә җаваплы карарга бурычлы. Бернәрсәне дә онытып калдырырга ярамый.

Әмма оештыру эшләреннән бигрәк, эш барышында бер кыенлык белән очрашабыз. Ул да булса, татар балалар бакчасы өчен бәйрәм сценарийларының җитәрлек булмавы. Булган очрак та да, тиешле таләпләргә җавап бирмәве. Алай гына да түгел, башка милләт балаларына тел өйрәнү авыр бирелгәнгә, үзебезгә сценарийларны табарга, тәрҗемә итәргә туры килде. Рус телендә булган материалга нигезләнеп, татар теленә тәрҗемә итеп, шигырь юлларына салдым. Шул рәвешле материал туплап, бәйрәм кичәләре әзерләдем. Бу хезмәт үзенә күрә заманча да, балалар өчен уңышлы да булды.

Әлеге сценарийлар ике телдә (татар, рус) алып барыла. Чөнки матур итеп татар телендә сөйләшүче балалар аз. Шул ук вакытта, әти-әниләр дә бәйрәм кичәсен аңлап, эшебездән канәгать калсын өчен эшләнелде.

**“Без инде хәзер зурлар...”**
**(“белем бәйрәме” көненә багышланган чара)**

**Максат:** Белем көне турында мәгълүмат бирү. Укытучы, тәрбияче һөнәренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**А.Б**. Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген!
Нәрсәдән бу? Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.
Исәнмесез, бәйрәмебез кунаклары, тәрбиячеләр, балалар.

Бездә бүген зур бәйрәм – “Белем көне” диләр аны. Бездә шушы матур бәйрәмне җыр белән каршы алыйк.

<u>**Җыр: “Өйрәтәләр мәктәпләрдә”**</u>

Балалар, әйдәгез әле бер уен уйнап алыйк, ул “**Бу – мин, бу – мин, минем якын дусларым”, - дип атала.**

**1.** Кем бүген иртән торып чиста итеп юынды?
**2.** Кем китаплар ярата, аларны саклап тота?
**3.** Кем уйнагач тәртипләп уенчыгын җыеп куя?
**4.** Кем әле тәртип бозып иптәшләрен рәнҗетә?
**5.** Кем эшчәнлекләрдә кул күтәреп, кычкырып җавап бирә?
**6.** Кем җәнлекләр ярата, алар өчен кайгырта?

Булдырдыгыз, балалар, ә хәзер, мин сезне белем иленә чакырам, ә анда безне белем ачкычы алып керер. Ой балалар, менә шушында гына куйган идем, кая булды икән ул?

<u>Китап тотып төлке керә, тәрбиячегә бәреләә.</u>

**Төлке:** Ой, исәнмесез.
**А.б.:** Исәнме, төлке, түрдән уз,
Бәйрәмгә дип килдеңме?
Нинди матур китап тоттың,
Укый да беләсеңме?
**Төлке:** Белем бабай бар дип әйтте,
Өйрән диде шушыны (китапка күрсәтә).
Укый белмим, кызыксынам,
Бик яратам китапны.
**А.б.:** Син бик вакытлы килгәнсең,
Белем бабай да хаклы.
Китап укый белгәннәрнең
Тормышта бик зур хакы.
Китаптан белем алабыз,
Өйрәнәбез барысын.
Бүген бездә белем көне
Кил, бәйрәмне карарсың.

Китап безнең якын дустыбыз, киңәшчебез, белем иленә алып керүче юлдашыбыз. Син безнең балаларны тыңлап кара әле, менә алар китапларны ничек яраталар.

**Китап турында шигырьләр сөйләнелә.**

<u>**Җыр: Әлифба**</u>

**Төлке:** Бик күңелле бәйрәмегез,
Җырлап, биеп аласыз.
Әйтегезче сез, балалар,
Әкият яратасыз?
Нинди төлкеләр бар икән,
Әкият дөньясында.
Бер уен да уйнап алыйк,
Тапкырлар арасында.

**1.** Әйтегез әле нинди әкиятләрдә төлке бар? (баларның җаваплары). Булдырдыгыз, бик күп әкиятләр беләсез икән.

**2.** Төлке нинди? (матур, хәйләкәр, житез...), менә сезнең житезлегегезне дә тикшереп карыйк әле.

**Уен: “Кем житез”**

Ике урындык астыннан җеп сузылган, ике бала көйгә биеп йөри , көй туктагач урындыкка утырып җепне татып алырга кирәк.

Уен азагында капчык тоткан бүре килеп керә.

**Бүре:** Нинди бәйрәм, нинди шау-шу,
Нәрсә бәйрәм итәсез.
Төлке дус та монда икән,
Каян килеп эләктең?
**Төлке:** Әй бүре, син икәнсең
Бездә белем бәйрәме.
Менә мин укый белмим,
Син укый беләсеңме?
**Бүре:** Кая инде укый белү,
Ишеттем генә әле.
Күбрәк алып кайтыйм диеп
Капчык китердем әле.
Сыяр микән шул капчыкка,
Әллә күбрәк булырмы?
Мин генә алып бетерсәм
Башкаларга калырмы?
**А.Б.:** Ай, бүре дус, бездә биргән
Белем сыймас капчыкка.
Тутырып та азапланма,
Йөрмәгәнсеңдер юкка.
**Бүре:** Капчык бәләкәй микән,
Әллә бирәсе килми?!
Белемле буласым килә,
Әллә ул шуны белми?!
**А.Б.:** Әй, бүре дус, белемне бит
Башка туплап куялар.
Бернинди дә капчык житмәс
Аны шунда салсалар.
Менә без, тәрбиячеләр,
Балалар арасында.
Яратырга өйрәтәбез,
Хәрефләрне танырга,
Табигатьне сакларга да,
Санарга да, язарга.
Бер-берсенә хөрмәт белән
Гел дусларча карарга.
Шуңа күрә капчыгыңны
Алып куй да бер читкә.
Балалар белән бергәләп,
Керик бераз тәртипкә.
Укырга да өйрәнерсең,
Яза белә башларсың.
Кызыклы китаплар укып,
Хәйран белем алырсың.

**Бүре:** Оятка калдым, балалар,
Ууууу, белмәдем, балалар....
**А.Б.:** Борчылырлык урын юк бит,
Бүре, син дә калышма.
Белемнәрне тикшерик тә,
Кил син безгә укырга.
**Уен: "Әнә килә гномнар"**
**Бүре:** Мин барысын белмәсәм дә,
Балалар булдыралар.
Капчыктагы табышмакка
Җавапны да табарлар.
Сынап карыйм әле сезне,
Табышмаклар чишегез.
Әгәр җавап табалсагыз,
Бер сюрпиз күрерсез.
**1.**Юк аягы, юк күзе
Сөйли өйрәтә үзе.
Телгә аннан оста юк.
Аннан якын дус та юк. (китап)
**2**. Кул белән чәчәсең,
Күз белән урасың. (язу, уку)
**3.**Үзе укый белмәсә дә
Гомер буе яза да яза. (ручка)
**4**. Сорыдыр төсе, үткендер теше,
Урманда йөри, бозаулар эзли. (бүре)
**Бүре:** Белдегез, булдырдыгыз.
**А.Б.:** Я, бүре дус, без дә синең
Биремнәрне үтәдек.
Син дә сүзеңдә тор инде,
Күрсәтче бүләгеңне.

**Бүре:** Әйе шул, менә мин нинди матур бер әйбер таптым. (капчыктан белем ачкычын чыгара).

**А.Б.:** Менә бит кайда югалган икән безнең Белем ачкычы, бир инде син аны безгә, бүре дус, бу бит безнең белем иленә алып керүче алтын ачкыч.

**Бүре:** Шулай мени? Алай булгач бер җырламый сезгә ачкыч юк.

**Җыр:**

Бүре ачкычны бирә.

**А.Б.:** Рәхмәт, бүре дус, ә хәзер, балалар, без сезнең белән белем иленә керергә әзер. Бәйрәмебез бик күңелле үтте, ә алда безне ел буе белем илендә кызыклы, ачышлар, очрашулар көтә. Бәйрәм белән сезне!

**"Ярый әле сез бар, кадерлеләребез!"**
***(Балалар бакчасында өлкәннәр көненә)***

**Максат**: Балаларны өлкәннәр көне белән таныштыру. Өлкәннәргә карата хөрмәт, ихтирам хисе тәрбияләү.

**А.Б.:** Хәерле көн, алтын көзләрдә аклык-сафлык бөркеп торучы дәү әниләребез-дәү әтиләребез, әби-бабаларыбыз, хөрмәтле өлкәннәребез! Бар тормышыгызны хезмәт белән бизәгән, зур эшләр башкарган кадерлеләребез, без сезгә бик рәхмәтле. Бүгенге бәйрәм

иртәсендәге котлауларыбыз сезнең өчен. Сөекле оныкларыгызның уңышларына сөенеп, бәйрәмебезнең кунагы булырга чакырабыз.

**Бала.** Тәрбияче апаларыбызның җылы теләкләренә кушылып, без дә сезгә кечкенә генә концерт тамашасы тәкъдим итәбез.

Дәү әни дә, әби дә сез,
Сөйкемле әни дә сез.
Сез булганга дөнья ямьле,
Йөзебез һәрчак нурлы.
Сездә мәңгелек шатлык,
Күзге муллык, язгы нур,
Кунакларыбызга багышлана
Дөньядагы иң матур җыр.

Җыр: "Әбием- дәү әнием".

**А.Б.:** Әлеге матур бәйрәмне бар җирдә бәйрәм итәләр. Өлкәннәребез олыгайдык дип күңелләрен төшермәсеннәр. Якыннарыбызга берсеннән- берсе матур шигырь бәйләмнәре бүләк итик.

**Шигырьләр:**

**1 бала.** Бакча бүген гөрләп тора,
Шаулап тора күгебез.
Без бит бәйрәмгә җыелдык,
Әллә шуны белмисез?
Кояш көлеп уянды да
Нурларын сипте мулдан.
Әбиләр килде бакчага,
Күзге кояшлы юлдан.

**2 бала.** Һәр җирдә бер хикмәт көтә:
Бүген гади көн түгел.
Бүген өлкәннәр бәйрәме,
Шуңа шатлана күңел.
Әбием, әбекәем, дип,
Дәшәмен сиңа кат-кат.
Бүген синең дә бәйрәмең
Шуңа безнең күңел шат.

**3 бала.** Син булганга, өйләр ямьле,
Нурлы һәрбер иртәләр.
Син өйрәткән догалар да
Уңышларга илтәләр.
Җылы сүзләр, изге теләк
Синең өчен уемда.
Сәламәт һәм көр күңелле
Бул син гомрең буена!

**4 бала.** Әби кеше гел яхшылык тели,
Гаебебез булса, кичерә
Гомер буе калыйк тугрылыклы
Әби дигән изге кешегә.
Яшәгез сез мәңге яшь булып
Туган йортыгызга ямь булып.
Сез булсагыз таза-сәламәт,
Оныкларыгызга булыр бик рәхәт.

**5 бала.** Оныкларга терәк булып,
Яшәгез сез шатлыкта.
Сәламәтлек, ак бәхетләр
Юлдаш булсын сезгә шатлыкта.
Картаймыйча шулай кояш кебек
Балкып торыгыз сез иртә-кич.
Яхшылыкны җирдә ятмый диләр
Онытмабыз сезне һич тә без.

**6 бала.** Бүген сөенә-сөенә
Шушы җырны җырлыйбыз.
Сезне кадерле әбиләр,
Бәйрәм белән котлыйбыз.

**Җыр: "Минем әби"**

**А.Б.:** Балалар, яраткан әбиләрегезне, кадерле бабаларыгызны матур шигырьләр белән сөендереп узыгыз әле.

**Шигырьләр:**

**1 бала.** Ак яулыклы, көләч йөзле,
Шат күңелле, әйбәт тә.
Кем ул, диеп сорыйсызмы?
Дәү әнием, әлбәттә.
Тәмле бәлеш пешерүче
Дәү әни безнең өйдә.
Аңардан ашарга сорый
Шаян песиебез дә.

**2 бала**. Өйгә кайтсам өй балкыган,
Өйгә нур иңгән!
Үзен ничек сагыннанны
Белгән ул белгән.

Ерак җирне якын итеп
Әбием килгән.
**3 бала.** Дөньяда иң җылы әби
Безнең әби, беләбез.
Шуңа күрә энем белән
Куенына керәбез.
**4 бала.** Иртән торсам, кояш чыгып,
Нурларын сипкән иде.
Әбиемнең чәе кайнап,
Коймагы пешкән иде.
**5 бала.** Күргәнем юк дәү әнинең
Тик утырып торганын.
- Ял ит инде арыгандыр
Аякларың, кулларың...

“Күрим әле улымны”- дип
Әбием килгән.
Дәү әнинең кочагында
Китәбез эреп кенә,
Яшәрбез әле үскәч тә
Кадерен белеп кенә.
Ашыгып, йөгереп кайтам өйгә
Тәмамлангач дәресләр.
Мине көтә син пешергән
Өчпочмаклар, бәлешләр.
Дәү әнием кет-кет көлеп,
– Бетсен инде эшем,- ди.
Эшсез торып, минем тизрәк
Картаясым килми, - ди.

**А.Б.:** Әнидән кала бу дөньяда безнең өчен иң кадерле кешеләр алар безнең әбиләребез. Бүген дә алар безгә җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләп, тәмле ашлар пешерәләр, матур гөлләр үстерәләр, үзләренең киңәшләре белән безгә һәрчак ярдәм итеп торалар.

Балалар, мин хәзер үзебезнең өлкән апаларыбызга менә шушы серле тартманы җибәрәм, алар шуңа үзләренең җылы теләкләрен, акыллы фикерләрен, торыш киңәшләрен салырлар.

*А.Б. Кунакларга шкатулка җибәрә, кунаклак аны кулдан-кулга күчереп сүзләрен әйтәләр.*

**А.Б.:** Карагыз ничек авырайган безнең серле татрма, без аны үзебездә саклап кына тотарбыз, кирәк вакытта акыллы киңәшләреннән файдаланырбыз.

- Гомерләре буе хезмәттә кайнаган, сугыш һәм сугыштан соңгы авырлыкларны иңнәрендә күтәргән, колхоз нужасын беренче көннәреннән үк тәртәгә җигелеп тарткан әби-бабаларыбыз картлык көннәрендә зур игътибарга, хөрмәткә лаек.

Рәхмәт сезгә, бу дөньяда куйган хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен. Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз

**Җыр: “Дәү әти”**

Бабаларыбызга хөрмәтне шигырьләребез аша җиткерик.

**Шигырьләр:**

**1 бала.** Исем китә безнең бабай
Җитмеш төрле һөнәр белә.
Каян болай, ничек алай?
Дисәң әгәр , көлә генә.
**2 бала.** Җитмеш төрле һөнәр белү-
Зур тырышлык хикмәте,- ди,-
Һөнәре юк кешеләрнең
Булмый иде икмәге, - ди.
**3 бала.** Безгә бүген кем килә?
Саескан күптән белә.
Өйдә пешә пәрәмәч,
Бәлеш исләре килә.
**4 бала.** Төрле- төрле бүләк алып,
Барча дуслар килгәннр.
Өлкәннәр кәне булганга,
Бәйрәмчә киенгәннәр

- Без, оланнар яшь чагында
Тырай тибеп йөрмәдек,- ди,
Әти нәрсә кушса, шуны
Иренмичә эшләдек, - ди.
Әйтсәм әйтим, - диде бабай,-
- Гомер буе гел эшле бул.
Иң- иң татлы, затлы җимеш-
- Тырыш хезмәт җимеше ул.
Килә ике әбием,
Килә ике бабаем.
Мин аларны яратам,
Һәрвакыт көтеп алам.
Прәнник, канфитлар куеп,
Чәй әзерләгән әби.
Курай уйный минем бабам,
Кунаклар бию бии.

**Бию**: Татар халык биюе

**А.б.:** Сәламәтлек ташламасын сезне,
Һәр көнегез үтсен шатлыкта.
Яшәү яме, дөнья иминлеге
Юлдаш булсын сезгә картлыкта- дигән теләкләрне “Йөрибез жир шары өстендә” жырына төреп кабул итегез.

**Жыр: “Йөрибез жир шары өстендә”**

Шушының белән безнең бәйрәмнең беренче өлеше тәмам, ә хәзер сезне чәй табыны янына көтеп калабыз.

**“Көзге серле агач” турында әкият**

Максат: Туган жиребезне ярату хисе, игенче хезмәтенә, икмәккә хөрмәт, халкыбызның милли йолаларына ихтирам тәрбияләү, белемнәрне шигырьләр, жырлар, табышмаклар, мәкальләр аша ныгыту. Балаларда күңел күтәренкелеге булдыру.

Искитмәле агач үсә,
Безнең капка төбендә.
Өрәңге, усак, миләш, имән,
Каен яфраклары эленгән.
Хаты да бар, укыйк әле,
Язган аны безгә көз.
“Күңелле ял итәр өчен,
Берәм-берәм яфрак өз”.

*1. Өрәңге яфрагы.*

Көз турында матур шигырь
Укыйсы бар бәйрәмдә.
Тизрәк концертны башлыйбыз,
Кичә булмый һәр көндә.
Шигырьләр.

| | |
|---|---|
| Көз килде. Үләннәр<br>Саргайды, шиңде.<br>Сап-сары яфраклар<br>Жиргә сибелде. (Ә. Ерикей.) | Кырлар буш кала,<br>Яңгырлар ява,<br>Жирләр дымлана, -<br>Бу кайчак була? *(Көз көне.)* |
| Вот художник так художник!<br>Все леса позолотил.<br>Даже самый сильный дождик<br>Эту краску не отмыл.<br>Отгадать загадку просим:<br>Кто художник этот? *(Осень!)* | Осень, осень, не спеши<br>И с дождями подожди.<br>Дай ещё нам лета,<br>Солнышка и света. |

*2. Имән яфрагы.*

Түгәрәккә басабыз да,
Кулларны тотышабыз.
Көз кунакка килгән чакта,
Матур итеп жырларбыз.
Жыр “Көз килде”.

| | |
|---|---|
| Алтын көз килде безгә,<br>Сары яфраклар жирдә.<br>Яңгыр ява тып-тып-тып,<br>Бөтен жирне чылатып. | Кошлар оча һавада<br>Жылы якларга таба.<br>Яз житкәч, алар бергә<br>Әйләнеп кайтыр безгә. |

Песня “Осень в гости к нам идёт”.

| | |
|---|---|
| Листик жёлтый, листик жёлтый<br>На дорожку упадёт.<br>Это значит, это значит<br>Осень в гости к нам идёт!<br>Припев:<br>*Приходи, красавица,<br>Осень золотая.<br>Деткам очень нравится<br>Осень золотая.* | Вот из тучки дождик, дождик<br>На ладошку упадёт.<br>Это значит, это значит<br>Осень в гости к нам идёт!<br>Припев:<br>*Приходи, красавица,<br>Осень золотая.<br>Деткам очень нравится<br>Осень золотая.* |

*3. Усак яфрагы.*
Яфракларны алыгыз,
Аннан бию башлагыз!
Пляска с листочками.

| | |
|---|---|
| Покачайся надо мной<br>Мой листочек золотой.<br>Листики дубовые,<br>Листики кленовые. | Вдруг веселый ветерок<br>Хочет вырвать мой листок<br>Листики дубовые,<br>*Листики кленовые.* |
| Мы за листиком сидим<br>Из-за листика глядим.<br>Листики дубовые,<br>Листики кленовые. | Мы листочек не дадим.<br>Пригодится нам самим<br>Листики дубовые,<br>Листики кленовые. |

*4. Миләш яфрагы.*
Карагыз әле бакчага,
Үсми монда ни генә?!
Ялкауланмыйча һәммәгез
Уңыш җыегыз, әйдә.
Җыр “Безнең бакча”.

| | |
|---|---|
| Бар матур бакча,<br>Анда кишер үсә.<br>Менә шундый кишер зур,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Кушымта:<br>*Кишер, кишер, кил әле,<br>Биеп , биеп кит әле.<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле.* | Бар матур бакча,<br>Анда суган үсә.<br>Менә шундый суган зур,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Кушымта:<br>*Суган, суган, кил әле,<br>Биеп , биеп кит әле.<br>Әллә-лә, әллә-лә,<br>Биеп, биеп кит әле.* |

*5. Юкә яфрагы.*
Табышмакны чишегез,
Аннан биеп бирегез!
Нам не страшен дождик злой,
Зонтик мы возьмём с собой.
И наденем мы на ножки
Свои новые... (*сапожки!*)

| | | |
|---|---|---|
| Вот на наших ножках<br>Новые сапожки.<br>Будем дружно мы шагать<br>По прямой дорожке.<br>Припев:<br>*Вот носок, каблучок,<br>Дружно прыгай: скок-скок-скок.* | Ох, какая лужа,<br>Но пройти нам нужно.<br>Шире, шире, шире шаг,<br>Мы шагаем дружно так!<br>Припев:<br>*Вот носок,* | Мокрые сапожки,<br>Ох, промокли ножки.<br>Надо, надо поплясать,<br>Надо ножки согревать.<br>Припев:<br>*Вот носок,* |

| | | |
|---|---|---|
| | *каблучок,*<br>*Дружно прыгай:*<br>*скок-скок-скок.* | *каблучок,*<br>*Дружно прыгай:*<br>*скок-скок-скок.* |

*6. Каен яфрагы.*
Аргансыздыр, ял итегез,
Балалар, сез дә бераз.
Бәйрәмебез дәвам итә,
Безне спектакль көтә.
Сценка.
*7. Тирәк яфрагы.*
Матур җырлар җырладыгыз,
Биедегез, уйнадыгыз.
Рәхмәт йөзеннән бүләккә
Миннән алма алыгыз.

**“Көзге төсләр”**
***(Кечкенәләр, уртанчылар төркеме өчен)***

**1 алып баручы.** Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
**2 алып баручы.** Көз көннәре килеп җитте,
Хушлашабыз җәй белән.
Бөтен җиргә яфраклардан
Алтын келәм җәелгән.

| | |
|---|---|
| Үтте-китте матур җәйләр,<br>Көзләр килеп җиттеләр.<br>Ак каенның яфраклары<br>Саргаешып киптеләр.<br><br>Сандугачлар, карлыгачлар<br>Очып китте еракка.<br>Торналар да ялга китте,<br>Җылы якка, көньякка. | Көннәр суынды,<br>Яфраклар сулды.<br>Көз җиттеме әллә –<br>Кошлар юк булды.<br><br>Кыйблага таба<br>Торналар оча.<br>Тауларны кара –<br>Болытлар коча.<br><br>Нинди салкын көз,<br>Тышта күңелсез!<br>Ничек яшәрбез<br>Чәчәксез, гөлсез? |

**ҖЫР.**

| | |
|---|---|
| Вот художник так художник!<br>Все леса позолотил.<br>Даже самый сильный дождик<br>Эту краску не отмыл.<br>Отгадать загадку просим:<br>Кто художник этот?<br>Осень! | Жёлтой краской кто-то<br>Выкрасил леса,<br>Стали отчего-то<br>Ниже небеса,<br><br>Ярче запылали<br>Кисточки рябин.<br>Все цветы увяли,<br>Лишь свежа полынь.<br><br>Я спросил у папы:<br>- Что случилось вдруг? |

| | |
|---|---|
| | И ответил папа:<br>- Это осень, друг. |

**ПЕСНЯ.**

**1 алып баручы.** Ишетәсезме, өйдә кемдер елый кебек...

*Ведущий стучит в окошечко. Из домика выходит заплаканная царица Осень.*

**Көзбикә.** Исәнмесез, хәерле көн!
Мин бу елыйм ялгызым.
Көне буе яңгыр коям,
Елгалар булып аксын!

**2 алып баручы.** Көзбикә, син нигә шулай күңелсезләндең?

**Көзбикә.** Бер бәхетсез Көзбикә мин.
Миңа һәрчак шундый күңелсез.
Аңламыйсыз минем хисләремне,
Чөнки минем хәлдә түгел сез.
Керпеләр кача, кошлар да
Жылы якка очалар.
Күңелсезләнми ни эшлим,
Барсы миннән качалар.

**1 алып баручы.** Нәрсә булды кинәт кенә?
Гүя кояш сүнде менә,
Көзбикә шундый моңсу,
Күңеле бик ямансу.

**Көзбикә.** Бушап калган иген басулары,
Жырлар тынган, сүнгән учаклар.
Куркынгандай көзге усал жилдән,
Дерелдәшеп тора усаклар.
Чуар күлмәк кигән моңсу урман,
Сары төсләр анда куерган.
Үпкәләгән төсле, бар табигать
Йөзен чыткан, кашын жыерган...
Ничә әйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

**2 алып баручы.** Көз күңелсез,
Урам ямьсез...
Нәрсә булды әле?
Тукта,
Болар бит һич түгел юкка.

**1 алып баручы.** Көзбикә үзен беркемгә дә кирәге юк дип уйлый, барысы да аннан качалар дип күңелсезләнә. Балалар, әйдәгез әле, бергәләп матур шигырьләр сөйләп алыйк, көз-елның иң матур фасылы бит ул.

| | |
|---|---|
| Кай ара жылы жил<br>Көньякка йөгерде?<br>Алмалар өлгерде,<br>Бакчага көз керде.<br><br>Тәмле ис урамның<br>Буеннан-буена.<br>Тыпылдап бакчада<br>Алмалар коела. | Алтын-сары яфракларны<br>Жилләр саный.<br>Иртән-кичен суык бабай<br>Бармак яный.<br><br>“Ник гомергә килми икән<br>Шушы язлар?!” –<br>Дигән кебек, моңсу гына<br>Китә казлар. |

| | |
|---|---|
| Ә кошлар көньякка<br>Китәргә җыена.<br>Күзләр соң шуңамы<br>Ямансу тоела? | Әнә инде юлга чыккан<br>Торналар да...<br>Бер үк сүзне кабатлыйлар,<br>Гүя, бар да:<br><br>Суык бабай артан житеп<br>Харап булмыйк,<br>Оча торыйк, тор-рыйк!<br>Тор-рыйк! |

**ЖЫР.**

| | |
|---|---|
| Ходит осень по дорожке,<br>Промочила в лужах ножки.<br>Льют дожди, и нет просвета.<br>Затерялось где-то лето.<br><br>Ходит осень, бродит осень.<br>Ветер с клёна листья сбросил.<br>Под ногами коврик новый,<br>Жёлто-розовый – кленовый. | И вправду осень так прекрасна!<br>И хризантемы в рост пошли...<br>Сияют солнышком небесным<br>Позолотевшие кусты...<br><br>Поют и радуются птицы,<br>Ловя последний теплый луч.<br>И вот к ногам твоим ложится<br>Кусочек радуги из туч... |

**ПЕСНЯ.**

Көзбикә. Нинди матур җыр! Нинди күңелле! Тик менә яңгырдан куркып, барлык җәнлекләр качып бетте: тиеннәр-имән куышына, куяннар-агач артына... И-и-и... *(Плачет.)*

**2 алып баручы.** Бөтенесе дә качмаган инде! Менә бу тирәдә бака сикереп йөри иде, ул бит суны ярата, көн буе уйнап ята!

**БАКАЛАР БИЮЕ.**

**Бака.** Бака-ка, бака-ка,
Елама инде юкка!
Минем арттан кабатла,
Бака-ка, бака-ка.
Көзбикә. Теләмим кабатларга,
Тотынам мин еларга!
*Выходят грибники с пустыми корзинками.*

**1 алып баручы.** Ой, нәрсә булды? Гөмбәчеләр түгелме соң болар. Тик нигәдер кәрзиннәре буш. Әллә бер гөмбә дә тапмаганнар инде?

**Гөмбәче.** Әйтерсең лә качыш уйный
Гөмбәләр безнең белән.
Мин ул шаян гөмбәләрне
Бик оста эзли беләм.

**Көзбикә.** Сез урман буйлап йөреп, бер гөмбә дә тапмадыгызмы?

**Гөмбәче.** Берне дә! Алар барысы да качып беткән.

**Көзбикә.** Ярар, мин сезгә булыша алам, борчылмагыз.
Гөмбәләр, җыелыгыз,
Бер биеп тә алыгыз! *(Хлопает в ладоши, выбегают грибочки.)*

**ГӨМБӘЛӘР БИЮЕ.**

**2 алып баручы.** Синнән башка гөмбә җыючылар нишләр иде икән? *(Көзбикәгә.)* Ә син көзне беркем яратмый дип уйлыйсың. Ялгышканыңны аңладыңмы? Көз бар кешегә дә кирәк.

**Көзбикә.** Ә мин кемгә кирәк?
Гөмбәчеләр *(поднимая полные корзинки).* Безгә!

**Тиен.** Миңа да!

**1 алып баручы.** Нинди шатлык, зур куаныч

Килгән тиенгә?
Сикергәләп, җырлап йөри
Урман көенә.
Җырлый-җырлый кабаланып,
Ул кая китә?
**Тиен.** Кышкылыкка азык җыеп,
Өемә илтәм. *(Гөлфия Юнысова)*
**ПЕСНЯ.**

**2 алып баручы.** Минем уйлавымча, син, Көз, бүген бераз киреләнәсең генә кебек... Безнең балалар синең кебек киреләр турында әкият тә беләләр.

Көзбикә. Әкиятнең азагы яхшы бетәме соң?
1 алып баручы. Хәзер беләсең инде.
2 алып баручы. Урманда кич, күк йөзендә
Йолдызлар балкып яна.
Бишек җыры көйләп,
Аю йоклата улын анда.
*Звучит колыбельная.*
Аю анасы. Чирәмгә коела күркә,
Йокла син улым, әйдә!
Аю баласы *(вскакивает, топает ногой)*.
Кирәкми миңа күркә!
**2 алып баручы**. Дип киреләнә иркә!
Әнисе чыкты юлга,
Чәчәк җыярга аңа.

*Медведица вперевалочку выходит на полянку, ее окружают девочки – цветочки.*

**ЧӘЧӘКЛӘР БЕЛӘН БИЮ.**
*Медведица выбирает «цветочек», подводит его к медвежонку.*
Аю анасы. Менә чәчәк сиңа,
Киреләнмә, йокла!
Аю баласы *(снова встает, топает ногой)*.
Кирәкми чәчәк миңа!
**2 алып баручы.** Дип киреләнгән була.
Әнисе чыга юлга,
Яфрак җыярга аңа!
*Девочки с листочками встают на танец.*
**ЯФРАКЛАР БЕЛӘН БИЮ.**
*Медведица даёт листочек медвежонку.*
**Аю анасы.** Менә яфрак сиңа,
Киреләнмә, йокла!
Аю баласы *(вскакивает)*. Кирәкми яфрак миңа!
**2 алып баручы.** Дип киреләнә менә!
Әнисе чыга юлга,
Юлыга шунда балга!
Алып кайтты бер тәпән,
Елама диде бүтән!
*Медведица вытаскивает бочонок, угощает медвежонка.*
**Аю баласы.** Нинди тәмле бал булды!
Күземә йокы тулды...
*Звучит колыбельная, медвежонок засыпает.*
**Көзбикә.** Мин дә бу аю баласы кебек киреләндем микәнни?

Мондый әкият тыңлагач,
Елавы да уңайсыз!
Тирә-якта барсы матур,
Көйсезләнү урынсыз!
Тирәндә кемдер еласа,
Бигрәкләр авыр икән...
Беркемне дә борчымам мин,
Тәртипсез булмам бүтән!
Бик зур рәхмәт сезгә, балалар!
Бакчабызда бәйрәм бүген.
Әйдәгез күңел ачыйк!
Бер-береңә шат елмаеп,
Барыбыз уйныйк-биик!
**БИЮ.**
**1 алып баручы.** Көз – моңсу чак, ямансу чак,
Көн дә ява яңгырлар.
Тик безнең бакчада һаман
Яңгырый дәртле җырлар!
**ҖЫР.**

**"Көзге төсләр" көз бәйрәме өчен:**
**1 алып баручы.** Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
**2 алып баручы.** Көз көннәре килеп житте,
Хушлашабыз җәй белән.
Бөтен жиргә яфраклардан
Алтын келәм җәелгән.

| | |
|---|---|
| Үтте-китте матур җәйләр,<br>Көзләр килеп життеләр.<br>Ак каенның яфраклары<br>Саргаешып киптеләр.<br><br>Сандугачлар, карлыгачлар<br>Очып китте еракка.<br>Торналар да ялга китте,<br>Җылы якка, көньякка. | Көннәр суынды,<br>Яфраклар сулды.<br>Көз життеме әллә –<br>Кошлар юк булды.<br><br>Кыйблага таба<br>Торналар оча.<br>Тауларны кара –<br>Болытлар коча.<br><br>Нинди салкын көз,<br>Тышта күңелсез!<br>Ничек яшәрбез<br>Чәчәксез, гөлсез? |

**ҖЫР.**

| | |
|---|---|
| Вот художник так художник!<br>Все леса позолотил.<br>Даже самый сильный дождик<br>Эту краску не отмыл.<br>Отгадать загадку просим:<br>Кто художник этот?<br>Осень! | Жёлтой краской кто-то<br>Выкрасил леса,<br>Стали отчего-то<br>Ниже небеса,<br><br>Ярче запылали<br>Кисточки рябин.<br>Все цветы увяли, |

| | |
|---|---|
| | Лишь свежа полынь.<br><br>Я спросил у папы:<br>- Что случилось вдруг?<br>И ответил папа:<br>- Это осень, друг. |

**ПЕСНЯ.**

**1 алып баручы.** Ишетәсезме, өйдә кемдер елый кебек....

*Ведущий стучит в окошечко. Из домика выходит заплаканная царица Осень.*

**Көзбикә.** Исәнмесез, хәерле көн!
Мин бу елыйм ялгызым.
Көне буе яңгыр коям,
Елгалар булып аксын!

**2 алып баручы.** Көзбикә, син нигә шулай күңелсезләндең?

**Көзбикә.** Бер бәхетсез Көзбикә мин.
Миңа һәрчак шундый күңелсез.
Аңламыйсыз минем хисләремне,
Чөнки минем хәлдә түгел сез.
Керпеләр кача, кошлар да
Җылы якка очалар.
Күңелсезләнми ни эшлим,
Барсы миннән качалар.

**1 алып баручы.** Нәрсә булды кинәт кенә?
Гүя кояш сүнде менә,
Көзбикә шундый моңсу,
Күңеле бик ямансу.

**Көзбикә.** Бушап калган иген басулары,
Җырлар тынган, сүнгән учаклар.
Куркынгандай көзге усал җилдән,
Дерелдәшеп тора усаклар.
Чуар күлмәк кигән моңсу урман,
Сары төсләр анда куерган.
Үпкәләгән төсле, бар табигать
Йөзен чыткан, кашын җыерган...
Ничә әйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

**2 алып баручы.** Көз күңелсез,
Урам ямьсез...
Нәрсә булды әле?
Тукта,
Болар бит һич түгел юкка.

**1 алып баручы.** Көзбикә үзен беркемгә дә кирәге юк дип уйлый, барысы да аннан качалар дип күңелсезләнә. Балалар, әйдәгез әле, бергәләп матур шигырьләр сөйләп алыйк, көз-елның иң матур фасылы бит ул.

| | |
|---|---|
| Кай ара җылы җил<br>Көньякка йөгерде?<br>Алмалар өлгерде,<br>Бакчага көз керде. | Алтын-сары яфракларны<br>Җилләр саный.<br>Иртән-кичен суык бабай<br>Бармак яный. |

| | |
|---|---|
| Тәмле ис урамның<br>Буеннан-буена.<br>Тыпылдап бакчада<br>Алмалар коела.<br><br>Ә кошлар көньякка<br>Китәргә җыена.<br>Көзләр соң шуңамы<br>Ямансу тоела? | “Ник гомергә килми икән<br>Шушы язлар?!” –<br>Дигән кебек, моңсу гына<br>Китә казлар.<br><br>Әнә инде юлга чыккан<br>Торналар да...<br>Бер үк сүзне кабатлыйлар,<br>Гүя, бар да:<br><br>Суык бабай артан җитеп<br>Харап булмыйк,<br>Оча торыйк, тор-рыйк!<br>Тор-рыйк! |

**ҖЫР.**

| | |
|---|---|
| Ходит осень по дорожке,<br>Промочила в лужах ножки.<br>Льют дожди, и нет просвета.<br>Затерялось где-то лето.<br><br>Ходит осень, бродит осень.<br>Ветер с клёна листья сбросил.<br>Под ногами коврик новый,<br>Жёлто-розовый – кленовый. | И вправду осень так прекрасна!<br>И хризантемы в рост пошли...<br>Сияют солнышком небесным<br>Позолотевшие кусты...<br><br>Поют и радуются птицы,<br>Ловя последний теплый луч.<br>И вот к ногам твоим ложится<br>Кусочек радуги из туч... |

**ПЕСНЯ.**

**Көзбикә.** Нинди матур җыр! Нинди күңелле! Тик менә яңгырдан куркып, барлык җәнлекләр качып бетте: тиеннәр-имән куышына, куяннар-агач артына... И-и-и... *(Плачет.)*

**2 алып баручы.** Бөтенесе дә качмаган инде! Менә бу тирәдә бака сикереп йөри иде, ул бит суны ярата, көн буе уйнап ята!

**БАКАЛАР БИЮЕ.**

Бака. Бака-ка, бака-ка,
Елама инде юкка!
Минем арттан кабатла,
Бака-ка, бака-ка.

**Көзбикә.** Теләмим кабатларга,
Тотынам мин еларга!

*Выходят грибники с пустыми корзинками.*

**1 алып баручы.** Ой, нәрсә булды? Гөмбәчеләр түгелме соң болар. Тик нигәдер кәрзиннәре буш. Әллә бер гөмбә дә тапмаганнар инде?

**Гөмбәче.** Әйтерсең лә качыш уйный
Гөмбәләр безнең белән.
Мин ул шаян гөмбәләрне
Бик оста эзли беләм.

**Көзбикә.** Сез урман буйлап йөреп, бер гөмбә дә тапмадыгызмы?

**Гөмбәче.** Берне дә! Алар барысы да качып беткән.

**Көзбикә.** Ярар, мин сезгә булыша алам, борчылмагыз.
Гөмбәләр, җыелыгыз,
Бер биеп тә алыгыз! *(Хлопает в ладоши, выбегают грибочки.)*

**ГӨМБӘЛӘР БИЮЕ.**

**2 алып баручы.** Синнән башка гөмбә җыючылар нишләр иде икән? *(Көзбикәгә.)*Ә син көзне беркем яратмый дип уйлыйсың. Ялгышканыңны аңладыңмы? Көз бар кешегә дә кирәк.

**Көзбикә.** Ә мин кемгә кирәк?

Гөмбәчеләр *(поднимая полные корзинки)*. Безгә!

**Тиен.** Миңа да!

**1 алып баручы.** Нинди шатлык, зур куаныч
Килгән тиенгә?
Сикергәләп, җырлап йөри
Урман көенә.
Җырлый-җырлый кабаланып,
Ул кая китә?

**Тиен.** Кышкылыкка азык җыеп,
Өемә илтәм. *(Гөлфия Юнысова)*

**ПЕСНЯ.**

**2 алып баручы.** Минем уйлавымча, син, Көз, бүген бераз киреләнәсең генә кебек... Безнең балалар синең кебек киреләр турында әкият тә беләләр.

**Көзбикә.** Әкиятнең азагы яхшы бетәме соң?

**1 алып баручы.** Хәзер беләсең инде.

**2 алып баручы.** Урманда кич, күк йөзендә
Йолдызлар балкып яна.
Бишек җыры көйләп,
Аю йоклата улын анда.

*Звучит колыбельная.*

**Аю анасы.** Чирәмгә коела күркә,
Йокла син улым, әйдә!
Аю баласы *(вскакивает, топает ногой)*.
Кирәкми миңа күркә!

**2 алып баручы.** Дип киреләнә иркә!
Әнисе чыкты юлга,
Чәчәк җыярга аңа.

*Медведица вперевалочку выходит на полянку, ее окружают девочки – цветочки.*

**ЧӘЧӘКЛӘР БЕЛӘН БИЮ.**

*Медведица выбирает «цветочек», подводит его к медвежонку.*

**Аю анасы.** Менә чәчәк сиңа,
Киреләнмә, йокла!
Аю баласы (*снова встает, топает ногой)*.
Кирәкми чәчәк миңа!

**2 алып баручы.** Дип киреләнгән була.
Әнисе чыга юлга,
Яфрак җыярга аңа!

*Девочки с листочками встают на танец.*

**ЯФРАКЛАР БЕЛӘН БИЮ.**

*Медведица даёт листочек медвежонку.*

Аю анасы. Менә яфрак сиңа,
Киреләнмә, йокла!
Аю баласы *(вскакивает)*. Кирәкми яфрак миңа!

**2 алып баручы.** Дип киреләнә менә!
Әнисе чыга юлга,
Юлыга шунда балга!

Алып кайтты бер тәпән,
Елама диде бүтән!
*Медведица вытаскивает бочонок, угощает медвежонка.*
**Аю баласы.** Нинди тәмле бал булды!
Күземә йокы тулды...
*Звучит колыбельная, медвежонок засыпает.*
**Көзбикә.** Мин дә бу аю баласы кебек киреләндем микәнни?
Мондый әкият тыңлагач,
Елавы да уңайсыз!
Тирә-якта барсы матур,
Көйсезләнү урынсыз!
Тирәндә кемдер еласа,
Бигрәкләр авыр икән...
Беркемне дә борчымам мин,
Тәртипсез булмам бүтән!
Бик зур рәхмәт сезгә, балалар!
Бакчабызда бәйрәм бүген.
Әйдәгез күңел ачыйк!
Бер-берeңә шат елмаеп,
Барыбыз уйныйк-биик!
**БИЮ.**
**1 алып баручы.** Көз – моңсу чак, ямансу чак,
Көн дә ява яңгырлар.
Тик безнең бакчада һаман
Яңгырый дәртле җырлар!
**ҖЫР.**

**Яңа ел могҗизасы "Лунтик"**
***(II кечкенәләр төркеме өчен яңа ел бәйрәме)***

Максат: Балаларда бәйрәм кәефе булдыру,сәләтләрен ачу. Иҗади мөмкинлекләрен үстерү.Дуслык, бердәмлек хисе тәрбияләү.

*Музыка астында, кулга-кул тотынышып, балалар залга керәләр.Чыршы тирәли түгәрәккә басалар. Алып баручы котлау сүзе әйтә.*

*Алып баручы.*Исәнмесез, балалар!
Яңа ел белән сезне!
Яңа ел котлы булсын!
Бәхетләр елы булсын!
*1.*Үсте чыршыбыз урманда,
Шаулап торды анда.
Җәен дә, кышын да зифа,
Матур ул һаман да.
*2.*Чыршы, чыршы, бизәлгәнсең,
Мәрҗәннәр элгәнсең.
Бик күп шатлыклар син безгә
Алып килгәнсең.

*Алып баручы.* Балалар, нишләптер безнең чыршыбызның утлары янмый. Әйдәгез әле, барыбыз бергә бик каты итеп кул чабыйк. Бәлки ул безгә үзенең серле утларын кабызыр.

*УЕН: чыршы утлары яна, аңа өрәләр, ул сүнә, тагын кул чабып утларны яндыралар.*

*3.*Әйдә, чыршы, түрдән уз,
Туңгансыңдыр, тиз җылын.
Җырла безгә быелгы
Дәртле Яңа ел җырын.
*4.*Тышта буран, бөтен җиргә
Карлар тутыра.
Безнең бүлмәдә бик матур
Чыршы утыра.
*5.*Күрегез чыршы апаны,
Матурланган, киенгән.
Безгә калын урманнан
Ул кунак булып килгән.
*ҖЫР.*
*6.* Опять зима, опять бело,
Вокруг сугробы намело.
Как будто белым мехом
Дома укрыты снегом.
*7.* У елочек макушки
В серебряной опушке.
А иней на березках,
Как праздничные блестки.
*8.*Давайте праздник продолжать,
Давайте петь и танцевать!
*ПЕСНЯ.*

*Балалар урындыкларга утыралар. Залның төрле урыннарына кечкенә чыршылар куела. Чыршының утлары сүнә.*

*Алып баручы.* Балалар, мин сезгә бер хикәя сөйләмәкче булам. Бервакыт Айда гадәти түгел бала туган. И шулай килеп чыккан – ул Җиргә ләккән, кая бик күп яңа дуслар тапкан. Ә нәрсә аннары булган, без хәзер белербез.

*Музыка яңгырый.*

*Лунтик.* Ой, минем яраткан җырым. Урманнан чыршы алып кайтырга вакыт җиткән бит.

*Лунтик көрәк белән чиләк ала.*

*Алып баручы.* Лунтик, ә нәрсәгә сиңа көрәк белән чиләк? Чыршыны бит пычкы белән кисәләр.

*Лунтик.*Мин аны кисмим. Мин аны казып алам. Ә бәйрәмнән соң кире урнына утыртып куям. Ярар, мин урманга киттем.

*Бу вакыт Лунтик чыршылар арасында – "урманда" йөри, бер чыршы янына килеп туктый.*

*Алып баручы.* Лунтик бер матур чыршы янына килеп туктагач, чыршы төбеннән бер Куян килеп чыга.

*Куян.* Минем яраткан агачны
Зинһар өчен алма син.
Мин бит шушы урманда
Чыршы төбендә яшим.

*Лунтик.* Ярый, ярый, Куянкай, алмыйм синең чыршыңны.

*Алып баручы.* Куян бик шатланган. Сөенеченнән үзенең балалары белән бии башлаган.

*КУЯННАР БИЮЕ*

*Алып баручы.*Лунтик юлын дәвам иткән. Зифа буйлы бер чыршы үсеп утыра юлында.Көрәк белән селтәнүе булган, агач төбеннән Төлке килеп чыккан.

*Төлке.* Ашыкмачы, әй Лунтик,
Бу чыршыны алма тор.
Бу чыршы матур түгел,
Әнә тегесе матур.

*Лунтик.* Ярый, Төлкебикә, ямьсез чыршы миңа кирәк түгел.

*Алып баручы.* Төлке бик шатланган, сөенеченнән үзенең дуслары белән бии башлаган.

*ТӨЛКЕЛӘР БИЮЕ.*

*Алып баручы.*Лунтик икенче чыршы янына барып казырга булган. Чыршы төбеннән Аю килеп чыккан да үкереп җибәргән.

*Аю.* Минем яраткан агачны
Зинһар өчен алма син.
Мин бит шушы урманда
Чыршы төбендә яшим.

*Лунтик.* Ярый, ярый, Аюкай, алмыйм синең чыршыңны.

*Алып баручы.* Аю бик шатланган, сөенеченнән үзенең дуслары белән бии башлаган.

*АЮЛАР БИЮЕ.*

*Алып баручы.* Шулай йөри торгач, Лунтик урмандагы бер йорт янына килеп җиткән.

*Лунтик.* Нинди матур йорт. Кем яши икән монда?

*Ишек шакый. Өйдән Кар кызы чыга.*

*Кар кызы.* Син кем?

*Лунтик.* Мин – Лунтик. Урман эчендә йөрим, үземә чыршы эзлим. Ә син кем?

*Кар кызы.* Мин – Кар кызы. Мин балалар бакчасына барырга җыенам, анда бүген Яңа ел бәйрәме. Аларның инде чыршылары да бар. Әгәр теләсәң, сине дә алып барам.

*Лунтик.*Әйе, минем бик барасым килә.

*Кар кызы.*Тукта әле, минем дусларым, кар бөртекләре, килеп җитмәгәннәр.
Кар бөртекләре, дусларым, очыгыз.
Кар бөртекләре, дусларым, биегез.

*КАР БӨРТЕКЛӘРЕ БИЮЕ.*

*Җәнлекләр.* Безне дә алыгыз бәйрәмгә.

*Кар кызы.* Әйдәгез, дусларым, әйдәгез.

*Чыршыны әйләнеп узалар, чыршыда утлар кабына.*

*Кар кызы.* Исәнмесез, балалар! Сез мине таныйсызмы? Мин – Кар кызы. Бу – Лунтик, ә болары – минем дусларым, урмандагы җәнлекләр. Балалар, ә кайда соң Кыш бабай? Әллә ул килеп җитмәде?

9. Суык бабай, кил безгә,
Яңа ел бәйрәменә,
Чыршы әйләнәсендә
Җыр җырлап әйләнергә.

*Кар кызы.* Кыш бабай ишетмәде, ахры, һаман килми. Әйдәгез, бергәләп чакырыйк Кыш бабайны.

*Барысы бергә.* Кыш бабай, а-а-у-у!

*Ишектә Кыш бабай күренә.*

*Кыш бабай.* А-а-у-у. Мин монда. Сезнең бакчаны бик озак эзләдем, сезнең тавышны ишетеп килдем. Исәнмесез, кунаклар, исәнмесез, балалар. Сезне Яңа ел белән котлыйм. Акыллы, дәү булып үсүегезне телим. Ә-ә, минем яраткан кызым да монда икән. Балалар ничек матур итеп киенгәннәр, ничек дәү үскәннәр. Ә чыршылары – минем урмандагы иң матур чыршы. Нинди матур итеп бизәлгән!

*Кар кызы.* Бөтен кеше ашкынып,
Сагынып көткән бәйрәм бу!
Кешеләргә Яңа ел
Алып килгән бәйрәм бу!
Котлы булсын Яңа ел!
Бәйрәм булсын мөбарәк!
Тотышыгыз кулга кул,
Ясап бәйләм-түгәрәк.

*ҖЫР.*

*УЕН "ӨШЕТӘМ".*

*А.Б.* Кыш Бабай, Кыш Бабай,
Кунакка килдең безгә.
Уйнадык та, җырладык та,
Бәлки биерсең син дә.

*Кыш Бабай.* Син дә, кызым, тик торма,
Аякларың тыпырдат.

*Кыш Бабай белән Кар Кызы бииләр.*

А.Б. Балалар, Кунакларыбыз ял итеп торсынннар, әле күп юл үтәселәре бар. Ә без сезнең белән аларга үзебезнең һөнәрләребезне күрсәтик.

*ШИГЫРЬЛӘР, ҖЫРЛАР, БИЮЛӘР.*

*Кыш бабай.*Күңелле булды бәйрәм,
Уйнадык әйлән-бәйлән.
Матур җырлар җырладык,
Кунак булып туймадык.
Тик китәр вакыт җитте.
Көтә безне янә юл.
Рәхмәт сезгә, балакайлар,
Котлы булсын Яңа ел!

*Бер бала.*Рәхмәт, бабай, сүзләреңә,
Бик матур теләкләрең.
Алып килдем, дигән идең,
Кайда соң бүләкләрең?

*Кыш Бабай.* Ай,кызым,оятлы була яздык бит. Кая соң әле безнең бүләкләр, кая гына калдырдык соң? Лунтикның чиләктә карыйк әле.

*Лунтик чиләктән бүләк чыгара. Кыш бабай бүләкләр өләшә.*

*Кыш бабай.* Сезнең белән күңелле
Булды безгә дә.
Бәхетләр генә телим
Һәммәгезгә дә.
Сукты китәр сәгатьләр,
Хушыгыз инде.
Яңа шатлыклар алып
Яңа ел килде.
Яңа елның таңнары
Гел аяз тусын.

Ул тарихка бәхет елы
Булып язылсын!
*Кар кызы.* Сау булыгыз! Бүгенгедәй
Һәрчак булыгыз көләч.
Күрешербез Яңа елда
Тагын да бер ел үткәч.
*Кыш бабай һәм Кар кызы китәләр.*
*Барысы бергә.* Хушыгыз, Кыш бабай! Сау булыгыз, Кар кызы!
*А.б.* Ә без, балалар, Кыш бабай һәм Кар кызы китте дип, күңелсезләнмик әле. Бәйрәмебез дәвам итә.
*Музыка яңгырый. Балалар чыгып китәләр.*

**“Сәгать телләре”**
***(зурлар төркеме өчен)***

| ... группа. | ... группа. |
|---|---|
| Каршылыйк, дуслар, бергәләп:<br>Яңа ел килә безгә!<br>Әнә күпме кунак килгән<br>Әйләнә-тирәбезгә.<br><br>Йолдызлар төшеп кушылган<br>Чыршыдагы утларга,<br>Кыш бабай белән Кар кызы<br>Килгән безне котларга.<br><br>Кыш бабай килгәч, булачак<br>Котлаулар да, бүләк тә!<br>Яңа елда чынга ашар<br>Безнең бөтен теләк тә!<br><br>Яңа елның бәхетле ел<br>Буласын без беләбез.<br>Шуңа күрә бергәләшеп<br>Яңа елга керәбез.<br><br>Рәхмәт сиңа да, иске ел!<br>Матур ел булдын бит син.<br>Синнән алган бәхет-шатлык<br>Гомер буена җитсен! | Безнең чыршыбызны бизәп,<br>Балкып кабына утлар,<br>Яңа елның башлануын<br>Хәбәр итә курантлар.<br><br>Кыш бабай, Кыш бабай<br>Безне бик ярата,<br>Ул безгә яңа ел<br>Бүләге тарата.<br><br>Ак чәчәк кебек кар ява<br>Урманнарга, кырларга.<br>Тынычлык алып Яңа ел<br>Килсен бөтен дөньяга. |

**Җыр.**

| | |
|---|---|
| Вот она, ёлочка наша,<br>В блеске лучистых огней!<br>Кажется всех она краше,<br>Всх зеленей и пышней.<br><br>В зелени прячется сказка:<br>Белая лебедь плывёт,<br>Зайчик скользит на салазках,<br>Белка орехи грызёт. | Снова пахнет свежей смолкой,<br>Мы у ёлки собрались,<br>Нарядилась наша ёлка,<br>Огоньки на ней зажглись.<br><br>Игры, шутки, песни, пляски!<br>Там и тут мелькают маски...<br>Ты – медведь. А я – лиса.<br>Вот какие чудеса! |

| | |
|---|---|
| Вот она, ёлочка наша,<br>В блеске лучистых огней!<br>Все мы от радости пляшем<br>В день новогодний под ней! | Вместе встанем в хоровод,<br>Здравствуй, здравствуй, Новый год! |

Песня.

*В углу стоит макет больших часов. Бьют куранты, стрелки с часов со стуком падают.*

А. Б. Бу нинди тавыш? Әллә сәгатебезнең уклары төшкән инде? Алай булса Яңа ел житүен ничек беләбез соң без?

*Из-за часов выбегают две «Стрелки» (девочки). Исполняют танец (см. программу «Ритмическая мозаика»).*

1 сәг. угы. Сеңелкәем, син кая?
Ярамый бит качарга.
Балалар жыелыштылар,
Биергә дип, жырларга.
Сәгать уклары булмаса,
Вакытны онытырлар.
Яңа елның житкәнен дә,
Белми, сизми калырлар.
2 сәг. угы. Ел да бер эш, уф, туйдырды,
Саныйсым килми бүтән.
Вакыт туктап калсын әнә,
Арыдым инде, китәм.
Үткәрсеннәр бәйрәмнәрен
Бездән башка бу юлы.
Искә алган кеше дә юк,
Түзәр чама калмады.
Кыш бабайны, Кар кызын да
Төшермиләр телдән дә.
Ял итәргә кирәк безгә
Тизрәк бул, киттек, әйдә!
*Убегают.*

А. Б. Болай булгач, Яңа елның килүен ничек беләбез инде? Балалар, борчылмагыз. Безнең әле вакыт бар, ничек тә табарбыз.

*Ищет стрелки: под елкой, под стульчиками детей, у родителей. Через зал пробегают Стрелки.*

1 сәг. угы. Сеңелкәем, син кая?
Вакыт йөгерә артка.

*Убегают. Дети показывают сценку «Звери проснулись», выносят зеленый коврик с «травой», цветами - «полянка». Наступает «лето». Время повернулось вспять.*

Аю. Ни булды монда кисәк?
Бар да үзгәрде кинәт.
Кыш килгән иде урманга,
Ничек түзәргә кызуга? Кызу миңа! *(Обмахивается лапами.)*
Куян. Ой, Аюкай, уяндыңмы?
Кояш нуры кагылдымы.
Миндә нинди үзгәреш,
Әллә нинди көнкүреш!?
Кардай ак иде туным,
Күр, кисәк соры булдым.

Бернәрсә дә аңламыйм!
Төлке килә, мин качыйм. *(Прячется за Медведя.)*
Төлке. Җылы тунымны кидем,
Бу эссегә чак түзәм!
Кыш килде дип торганда,
Җәй башланды урманда.
Керпе. Тәртипсезлек! Ни булды?
Кемгә ни ошамады?
Төлке, син күрмәдеңме?
Ни булды, белмәдеңме?
Төлке. Юк, күрмәдем! Үземдә
Аптырыйм бу хәлләргә.
Әле генә кыш иде,
Кар көртләре күп иде.
Кисәк бар да үзгәрде,
Вакыт артка йөгерде.
Аю. Кем шаярта, ни өчен,
Бетерде барлык көчем.
Бу вакытта гадәттә,
Йокларга тиеш бит мин.
А. Б. Балалар! Сәгать уклары барысын да бутаган. Кыш урына җәй килде. Аюга ничек ярдәм итәргә икән? Безнең балаларыбыз сиңа кышкы бию биеп күрсәтерләр! Бәлки сиңа салкынрак булып китәр!
*Танец «Зимушка-зима» (музыка по выбору). Появляются Стрелки.*
Куян. Ой, күрегез-чибәрләрне,
Матур ике сеңелкәйне!
Сәг. уклары. Исәнмесез, дусларым,
Бераз югалып тордык.
Тавышыгыз ишеттек,
Менә килеп тә җиттек.
Сез, җәнлекләр, борчылмагыз,
Өегезгә кайтыгыз.
Кыш бабайны табарбыз,
Шушында кайтарырбыз.
1 сәг. угы. Күрәсеңме, син ни майтардың?
2 сәг. угы. Әйе, мин аңладым. Безгә тизрәк сәгатебезгә кайтырга кирәк, алайса соң булуы мөмкин!
*Стрелки уходят. Появляются Лиса Алиса и Кот Базилио.*
Алиса. Ашыйсым килә, ардым... *(Садится.)*
Тагы мине алдадың.
Кафе бар дигән идең,
Инде күпме юл килдек!
Базилио. Булды, Төлке, түз бераз,
Нидер күрәм еракта. *(Всматривается.)*
Әнә киләләр икәү,
Ахрысы, безнең якка.
Алиса. Дускай, торырга булыш! *(Встает, смотрит.)*
Базилио, ни булды сиңа? *(Разочарованно.)*
Болар сәгать уклары,
Аны ашап буламы?
Без бит ит яратабыз,
Тимерне ашамыйбыз. *(Таинственно.)*

Туды миндә бер план,
Уем булса да яман,
Сәгать телләрен күмик,
Бераз гына су сибик.

Базилио*(мечтательно)*. Һәм алар үсеп җитәр,
Алтын булсалар икән!

А. Б. Туктагыз, туктагыз, Базилио һәм Алиса. Безнең сәгать укларын күмәргә ярамый. Без алардан башка Яңа елны ничек каршыларбыз. Иң яхшысы, безнең балаларның биюләрен карап үтегез.

*Танец по выбору музыкального руководителя.*

Песи һәм төлке. Ә без барыбер аларны күмәчәкбез.

*Хватают стрелки, накрывают их покрывалом, берут ведра и убегают за водой. Выходят две Вороны (девочки).*

1 нче карга. Син күрдеңме?
2 нче карга. Барсын да күрдем.
1 нче карга. Син ишеттеңме?
2 нче карга. Барысын да ишеттем.
1 нче карга. Сәгать укларын коткарып,
Булышыйк без дусларга.
Песи һәм төлкене шушылай
Утыртыйк без акылга.

*Вороны сбрасывают покрывало.*

Сәг. уклары. Бик зур рәхмәт, сезгә, мәрхәмәтле каргалар!
Каргалар. Ашыгыгыз, алайса соңга каласыз.

*Вороны садятся на свои места. Стрелочки бегут и прячутся за большие часы. Там незаметно прикрепляют «упавшие» стрелки. Звучит бой курантов. Входят Дед Мороз и Снегурочка.*

Кыш бабай. Исәнмесез, балалар!
Юксынмагыз, килдем мин.
Миннән башка бәйрәм булмас,
Көтәсездер, дидем мин.
Күрәм, чыршыгыз бизәлгән,
Сез дә үсеп җиткәнсез.
Рәхмәт сезгә, балалар,
Мине сагынып көткәнсез!
Кар кызы. Бөтен кеше ашкынып,
Сагынып көткән бәйрәм бу!
Кешеләргә Яңа ел
Алып килгән бәйрәм бу!
Котлы булсын Яңа ел!
Бәйрәм булсын мөбарәк!
Тотышыгыз кулга кул,
Ясап бәйләм-түгәрәк.
Алып баручы.Тукта, тукта, Кар кызы,
Оныттык без бер эшне.
Балкып торырга тиеш
Безнең Чыршы бу кичне!
Вакыт җитте, Кыш бабай,
Кабыз Чыршы утларын.
Җем-җем итеп балкысын
Нурга төреп Җир шарын!
Кыш бабай. Яшел Чыршы, бизәнеп

Быел тагын килгәнсең.
Синсез бәйрәм күңелсез
Булыр иде, беләмсең?
Җырлап-биеп тирәндә
Әйлән-бәйлән уйнарга
Күрәсеңме, никадәр
Нәни дустың җыйналган?!
Бизәкләрең тагын да
Матуррак балкысын,
Сәйләннәрең нур сипсен,
Җем-җем утлар кабынсын!
*Чыршыда утлар кабына.*
Алып баручы. Рәхмәт, Чыршыкай!
Рәхмәт, Кыш бабай!
Җырларга оста
Барча кыз-малай!
Куллар тотыштык,
Дуслар, әйдәле.
Чыршы тирәли
Җырлап әйләник.
Җыр.
Песня.

Кыш бабай. Сез, балалар, әйтегезче, куркасызмы салкыннан? (Юк.)

Кил әле миңа таба,
Тотып карыйм кулыңнан.
Уен.
Кыш бабай. Әйлән-бәйлән уйнадык,
Биедек тә, җырладык.
Инде хәзер балалар,
Шигырь сөйләп карарлар.

| | |
|---|---|
| Кыш бабай, Кыш бабай,<br>Исән-сау килденме?<br>Син бездә Яңа ел<br>Икәнен белдеңме?<br><br>Белдеңме син безнең<br>Сагынып көткәнне?<br>Үзең дә көттеңме<br>Яңа ел җиткәнне?<br><br>Без көттек бик күптән<br>Яңа ел килә, дип.<br>Сиңа дип сөйләргә<br>Шигырҗләр өйрәндек.<br><br>Кулга-кул тотышып<br>Ясыйк та түгәрәк,<br>Әйдә, кил, Кыш бабай,<br>Әйләник бергәләп.<br><br>Яңа ел сиңа да | Безгә Кыш бабай килгән,<br>Яңа ел алып килгән.<br><br>Капчыгына күп итеп<br>Бүләкләр салып килгән.<br><br>Көттек сине сагынып,<br>Исән-саумы, Кыш бабай!<br>Өләш бүләкләреңне,<br>Капчыгыңны чиш, бабай! |

| | |
|---|---|
| Сөенеч китерсен.<br>Тагын бер ел үткәч<br>Яңадан килерсең! | |
| Мы весной его не встретим,<br>Он и летом не придёт,<br>Но зимою к нашим детям<br>Он приходит каждый год.<br><br>У него румянец яркий,<br>Борода, как белый мех,<br>Интересные подарки<br>Приготовит он для всех.<br><br>С Новым годом поздравляя,<br>Ёлку пышную зажжёт,<br>Ребятишек забавляя,<br>Встанет с нами в хоровод.<br><br>Дружно мы его встречаем,<br>Мы большие с ним друзья...<br>Но поить горячим чаем<br>Гостя этого нельзя! | - Кто в нарядной тёплой шубе,<br>С длинной белой бородой,<br>В Новый год приходит в гости,<br>И румяный, и седой?<br><br>Он играет с нами, пляшет,<br>С ним и праздник веселей!<br>- Дед Мороз на ёлке нашей<br>Самый главный из гостей! |

*Звучит фонограмма: скрежет металла.*

Кар кызы. Тагы сәгать телләре күңелсезләнәме әллә? Карап килим әле. *(Открывает часы.)*Монда Кыш бабабызның бәйрәм күчтәнәчәре икән! Бабай, син балаларга сюрприз әзерләгәнсең!

Кыш бабай. Әлбәттә, кызым.

*Раздают подарки.*

Кыш бабай. Сезнең белән күңелле
Булды безгә дә.
Бәхетләр генә телим
Һәммәгезгә дә.
Сукты китәр сәгатьләр,
Хушыгыз инде.
Яңа шатлыклар алып
Яңа ел килде.
Яңа елның таңнары
Гел аяз тусын.
Ул тарихка бәхет елы
Булып язылсын!

Кар кызы. Сау булыгыз! Бүгенгедәй
Һәрчак булыгыз көләч.
Күрешербез Яңа елда
Тагын да бер ел үткәч.

*Прощаются с детьми и уходят.*

Алып баручы. Ә хәзер саубуллашырга вакыт! Котлы булсын Яңа ел! Барыгызны да бәйрәм белән!

**КӨЛГЕНӘ**

***(Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен яңа ел сценарие)***

Алып баручы.
Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

| ... группа. | ... группа. |
|---|---|
| Янә бер ел артта калды,<br>Калды артта моңаеп...<br>Ниләр безгә вәгъдә итә? –<br>Алдыбызда Яңа ел!<br><br>Булыр микән йөзе һәрчак<br>Кояш кебек гел көләч?<br>Куандырыр микән безне<br>Һәрбер көне – ул килгәч?!<br><br>И Яңа ел, балкып кил син,<br>Шатлык белән генә кил:<br>Әтиләр дә, әниләр дә,<br>Бабайлар да, әбиләр дә,<br>Һәм, әлбәттә, сабыйлар да<br>Сөенсеннәр гелән-гел!<br>Хуш киләсең, Яңа ел! | Яшел чыршы, тезелешеп<br>Әйләнәбез тирәңдә.<br>Куанабыз яңа елга<br>Син кунакка килгәнгә.<br><br>Җәй көне җиләк җыярга<br>Урманга барган идек,<br>- Ямьле чыршы, яңа елга<br>Кунак булып кил, - дидек.<br><br>Рәхмәт, менә син килгәнсең,<br>Әйләнәбез тирәңдә.<br>Яңа һөнәрләр өйрәндек,<br>Яңа елга кергәндә. |

Җыр “Чыршы әйләнәсендә”.

| ... группа. | ... группа. |
|---|---|
| Вот она, ёлочка наша,<br>В блеске лучистых огней!<br>Кажется всех она краше,<br>Всх зеленей и пышней.<br><br>В зелени прячется сказка:<br>Белая лебедь плывёт,<br>Зайчик скользит на салазках,<br>Белка орехи грызёт.<br><br>Вот она, ёлочка наша,<br>В блеске лучистых огней!<br>Все мы от радости пляшем<br>В день новогодний под ней! | Снова пахнет свежей смолкой,<br>Мы у ёлки собрались,<br>Нарядилась наша ёлка,<br>Огоньки на ней зажглись.<br><br>Игры, шутки, песни, пляски!<br>Там и тут мелькают маски...<br>Ты – медведь. А я – лиса.<br>Вот какие чудеса!<br><br>Вместе встанем в хоровод,<br>Здравствуй, здравствуй,<br>Новый год! |

Песня «Новогодняя песенка».
Алып баручы.
Борын-борын заманнарда
Әле без дә туганчы.
Кызы Көлгенәсе белән
Яшәгән бер урманчы.
Рәхәт, матур яшәгәннәр,
Кыз әтисен яраткан.
Әтисе аңа урманнан,
Чәчәкләр алып кайткан.

Тик бер вакыт шушы йортның
Бөтен яме югала.
Кызларын ияртеп монда
Килгән ди үги ана.
Яратмый ул Көлгенәне,
Кешегә дә санамый.
Бөтен эшне аңа куша,
Әйтеп куя: бер минутта
Тик торырга ярамый!!!
Танец глашатаев.
1 глашатай.
Һәммәгезне, һәммәгезне,
Чакырабыз бәйрәмгә.
Яңа елны иң элек,
Каршылыйк без биредә.
2 глашатай.
Уздырыйк шундый бәйрәм,
Һәр кеше калсын хәйран.
Җыр-бию гөрләп торсын,
Йөзләр, көләч, шат булсын!
3 глашатай.
Бар кеше хөрмәтенә
Оештырабыз бәйрәм.
Һичкем битараф калмасын,
Җырласын да, биесен!
*Көлгенә керә.*
Көлгенә.
Җитә яңа ел бәйрәме,
Барсы да күңел ача.
Минем барасы килгәнгә
Әти риза, ичмаса!
Тик җибәрми үги анам,
Эшләр күп дигән була.
Болай булса, бер бүләксез,
Калырмынмы бу елда???
*Көлгенәнең уги әнисе белән ике кызы керә.*
Үги әни.
Көлгенә дим, Көлгенә,
Бигрәк ялкау да үзең.
Кая безнең калфаклар,
Тәмам бетте сиңа түзем.
Җырлап йөргән буласың,
Әйтерсең файда була?
Без бәйрәмгә киткәч тә,
Бар эш тә сиңа кала!
Көлгенә.
Әзер, хәзер китерәм,
Менә калфак-күлмәкләр!
Бәйрәм кичендә булырсыз,
Сез, мөгаен чибәрләр.
Үги әни.
Онытмадыгызмы икән,

Сез нишләргә кирәкне?
Кыш бабайның бүләгенә
Лаек булыр икәнне.
Кызлар.
Юк, әнием, онытмадык,
Барысын да беләбез:
Биергә, шигырь сөйләргә,
Җырларга да әзер без.
*Көлгенә калфакларны китерә.*
Кызлар.
Ай! Нинди матур! Бир тизрәк!
Мин иң чибәре, димәк!
Үги әни.
Ярый, тырышкансың, син дә чыршы бәйрәменә барырсың.
Көлгенә. Чынлапмы?
Үги әни. Тик эшләрең беткәч кенә!
Көлгенә. Нинди эшләр?
Үги әни.
Алып мен баздан кишерне,
Карны ялт итеп көрә.
Югалган мәрҗәнне табып,
Шкатулкага сал, менә!
Шуларны эшләп бетерсәң,
Зур бәйрәмгә рәхим ит!
Ә хәзергә без җыенйик,
Ә син эшкә чыгып кит!
Әйдәгез, кызларым, киттек.
Көлгенә.
Беләм, бәйрәм башланды,
Эш өстенә эш миндә.
Ничек өлгерермен икән,
Инде хәзер белмим дә.
*Көлгенә утырып елый.*
Кар бөртекләре биюе.
Кар бөртеге.
Син, Көлгенә, елама,
Ярдәмемне кызганмам.
Яңа ел бәйрәменә,
Тылсымлап озатып куям!
Көлгенә. Ничек? Миңа бит уги әни шундый күп эш бирде.
Кар бөртеге.
Мин кар бөртеге булсам да
Булышыймчы дустыма.
Әкияттәге тылсымнарны
Ашырыймчы тормышка.
Куянкайлар, чыгыгыз!
Эшне тизрәк башлагыз
Баздан алып кишерләрне
Тизрәк урнаштырыгыз
*Куяннар чыга.*
Куяннар.
Хәзер эшли башларбыз

Баздан алып кишерләрне
Тизрәк урнаштырырбыз.
Кар бөртеге.
Кошкайлар, җитезләр,
Тизрәк очып килегез
Мәрҗәннәрне табып алып
Шкатулкага салыгыз.
*Кошлар очып чыга.*
Кошлар.
Тизрәк очып киләбез
Мәрҗәннәрне табып алып
Шкатулкага салабыз.
*Эшнең башкаруы турында хәбәр итәләр.*
Көлгенә.
Ләкин бит минем бәйрәмгә барырга матур күлмәгем дә юк.
Бик тә барасым килә шул,
Яңа ел бәйрәменә!
Бар эшләрем эшләнсә дә,
Барып булмады менә!
*Кар бөртекләре Көлгенәгә матур күлмәк бирәләр.*
Кар бөртеге.
Ә хәзер бар балга син,
Күңел ач бер туйганчы.
Син йөри аласың анда,
Нәкъ унике тулганчы.
Чөнки унике тулуга,
Бар тылсым көчен җуя.
Җитез атла, башмакларың
Барысы юкка чыга.
Онытa күрмә, Көлгенә,
Мондый төн ул бер генә!
Нәкъ унике тулуга,
Барысы юкка чыга.
Көлгенә. Рәхмәт сезгә, дусларым! Мин шундый бәхетле.
Алып баручы. Әйдә, Көлгенә, Чыршы бәйрәменә рәхим ит!
*Патша улы Көлгенә белән очрашалар.*
Патша улы.
Исәнмесез, чибәр туташ,
Әйдәгез, бергә биик.
Шушы яңа ел төнендә,
Иң матур теләк телик!
Биюләр.
*Сәгать сукканы ишетелә.*
Көлгенә.
Сәгать суга уникене,
Кай ара вакыт үтте?
Әйткәннәрен үтәмәсәм,
Көлкегә калам инде.
Патша улы.
Ашыкма, таныш түгел кыз,
Бәйрәм итик, калыгыз.
Әле биеп өлгермәдек,

Сүземә колак салыгыз!

*Ут сүнә. Көлгенә чыгып йөгерә,туфлие төшеп кала.*

Патша улы.
Хәзер генә шунда иде
Кая китте бу гүзәл
Исемен дә белә алмадым
Шунысы да бик җәл.

Алып баручы.
Әй, ханым син, солтаным,
Бу әкият бик таныш.
Бәйрәмгә килгән кызларга
Туфли киеп карарга куш.
Кайсысына ярый калса,
Көлгенә дип беләчәк.
Патша улы аңа шундук
Бу кичтә өйләнәчәк.

*Үги әнисе белән ике кызы керә.*

Кызлар.
Без киябез, безгә ярый,
Туфлиләре бер дигән.
Патша улына хатынга
Бездәй кем бар пар килгән?

*Патша улы туфлине кызларга кигезеп карый.*

Алып баручы.
Ярамады сезгә туфли,
Кимәсәгез дә булган!
Сезнең кебек матурларга
Әнә солдат та таман!

Үги ана.
Мин дә киям, бәлки миңа,
Ярарлыктыр бу туфли.
Минем кызларга ярамый
Дип әйтәсездер юри.

Алып баручы.
Ханым сезнең аякка ул
Бөтенләй дә ярамый.
Сезгә генә бирер идек,
Бернигә дә карамый.

*Патша улы туфлине икенче кызларга кигезеп карый. Кар бөртеге керә.*

Кар бөртеге.
Хөрмәтле Принц! Бүген бәйрәм,
Яңа ел килә безгә.
Кыш бабайны чакырыйкмы
Әллә бераз ярдәмгә?
Балалар, әйдәгез, бергәләп, Кыш бабайны чакырыйк.

*Кыш бабай белән Көлгенә керәләр.*

Патша улы.
Менә ул бәллүр туфли,
Дустым, тизрәк үзең ки!

Кыш бабай.
Могҗизалар күтә һәркем,

Яңа ел бәйрәмендә.
Кабат очраша чын дуслар,
Чыршы әйләнәсендә.
Көлгенә.
Бөтен кеше ашкынып,
Сагынып көткән бәйрәм бу!
Кешеләргә Яңа ел
Алып килгән бәйрәм бу!
Котлы булсын Яңа ел!
Бәйрәм булсын мөбарәк!
Тотышыгыз кулга кул,
Ясап бәйләм-түгәрәк.
Алып баручы.
Тукта, тукта, Көлгенә,
Онытtык без бер эшне.
Балкып торырга тиеш
Безнең Чыршы бу кичне!
Вакыт житте, Кыш бабай,
Кабыз Чыршы утларын.
Жем-жем итеп балкысын
Нурга төреп Жир шарын!
Кыш бабай.
Яшел Чыршы, бизәнеп
Быел тагын килгәнсең.
Синсез бәйрәм күңелсез
Булыр иде, беләмсең?
Жырлап-биеп тирәндә
Әйлән-бәйлән уйнарга
Күрәсеңме, никадәр
Нәни дустың жыйналган?!
Бизәкләрең тагын да
Матуррак балкысын,
Сәйләннәрең нур сипсен,
Жем-жем утлар кабынсын!
*Чыршыда утлар кабына.*
Алып баручы.
Рәхмәт, Чыршыкай!
Рәхмәт, Кыш бабай!
Жырларга оста
Барча кыз-малай!
Куллар тотыштык,
Дуслар, әйдәле.
Чыршы тирәли
Жырлап әйләник.
Жыр “Кыш бабай”.
Песня “К нам приходит Новый год”.
Кыш бабай. Сез, балалар, әйтегезче, куркасызмы салкыннан? (Юк.)
Кил әле миңа таба,
Тотып карыйм кулыңнан.
Уен.
Кыш бабай. Әйлән-бәйлән уйнадык,

Биедек тә, җырладык.
Инде хәзер балалар,
Шигырь сөйләп карарлар.
*Балалар шигырьләр сөйлиләр.*

| ... группа. | ... группа. |
|---|---|
| Кыш бабай, Кыш бабай,<br>Исән-сау килденме?<br>Син бездә Яңа ел<br>Икәнен белдеңме?<br><br>Белдеңме син безнең<br>Сагынып көткәнне?<br>Үзең дә көттеңме<br>Яңа ел җиткәнне?<br><br>Без көттек бик күптән<br>Яңа ел килә, дип.<br>Сиңа дип сөйләргә<br>Шигырьләр өйрәндек.<br><br>Кулга-кул тотышып<br>Ясыйк та түгәрәк,<br>Әйдә, кил, Кыш бабай,<br>Әйләник бергәләп.<br><br>Яңа ел сиңа да<br>Сөенеч китерсен.<br>Тагын бер ел үткәч<br>Яңадан килерсең! | Дед Мороз из зимней сказки<br>Вёз на праздник к нам салазки.<br>На салазках тех – игрушки:<br>Куклы, мячики и клюшки...<br><br>У Снегурочки-малышки<br>Есть друзья: ежи, зайчишки,<br>Белки, мишки и лисички,<br>Желтогрудые синички...<br><br>Всех на праздник приглашаем.<br>Приходите, мы вас ждём!<br>Добрым словом и вниманьем<br>Никого не обойдём.<br><br>Безгә Кыш бабай килгән.<br>Яңа ел алып килгән.<br>Капчыгына күп итеп<br>Бүләкләр салып килгән.<br><br>Көттек сине, сагынып,<br>Исән-саумы, Кыш бабай!<br>Өләш бүләкләреңне,<br>Капчыгыңны чиш, бабай! |

Кыш Бабай. Ай, кызым, оятлы була яздык бит. Кая соң әле безнең бүләкләр, кая гына калдырдык соң?

Көлгенә. Бабакай, хәзер нишлик,
Бүләкне кайдан эзлик?
Кыш Бабай. Әй, Көлгенә, елама.
Мин булганда янында.
Берни эзсез югалмас,
Бүләк табылмый калмас.
Әфсен-төфсен,
Кар бөртеге тизрәк килсен
Бүләкләрне балаларга
Өләшергә китерсен.
*Кар бөртеге керә. Кыш Бабай белән Кар кызы бүләк өләшәләләр.*
Кыш бабай. Сезнең белән күңелле
Булды безгә дә.
Бәхетләр генә телим
Һәммәгезгә дә.
Сукты китәр сәгатьләр,
Хушыгыз инде.
Яңа шатлыклар алып
Яңа ел килде.
*Кыш бабай китә.*

Алып баручы. Ә хәзер саубуллашырга вакыт! Котлы булсын Яңа ел! Барыгызны да бәйрәм белән!

## “Чуар Тавык”

***(II кечкенәләр төркемендә 8 нче март бәйрәменә сценарий)***

Максат: Балаларны тәрбияләү нигезендә,аларны әниләрен ихтирам итәргә, яратырга өйрәтү.Туган телендә күнекмәләр,туган иленә,туган жиренә,әти-әнисенә мәхәббәт хисләрен ныгыту.

*Алып баручы:* Хәерле көн, безнең иң кадерле кунакларыбыз – әниләр,әбиләр! Сезне барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз. Һәрвакыт шат, сәләмәт, бәхетле булыгыз. Балаларыгызның бүгенге чыгышы сезгә бәйрәм бүләге булсын.

Нигә бүген бөтен жирдә
Чәчәкләр балкый бездә?
Нигә кояш көлеп карый –
Беләбез һәммәбез дә.
Бүген – әниләр бәйрәме,
Бүген жирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.
Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Жирдә барлык балалар.
Мин дә котлыйм, әнкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә!

*Жыр.*

В день весенний, солнечный
Маму поздравляем.
Жизни долгой, радостной
От души желаем!
Слушай нашу песенку,
Мамочка любимая,
Будь всегда здоровая,
Будь всегда счастливая!

*Песня.*

А теперь мы спляшем,
Праздник будет краше!

*Танец*

*Алып баручы:* 8 нче Март – үзенә курә бер үзенчәлекле матур бәйрәм инде ул. Бу көнне һәркем үз әнисен бәйрәм белән котлый. Ә менә кем ничек котлый, хәзер шуны карап үтик.

*Музыка астында Чуар тавык һәм чебешләр керәләр.*

*Чуар тавык.* Мин бәхетле чуар тавык,
Чебешләрем янымда.
Күп түгелләр биш бөртек,
Кирәк санап карарга.
Берәү, икәү, ... ой, белмимен бит калганын...

*А.Б.* Балалар, әйдәгез, Чуар Тавыкка чебешләрен санарга ярдәм итик.

*Балалар күмәкләп 5 кә кадәр саныйлар.*

*Чуар тавык.* Менә хәзер мин сезнең барыгызны да саныйм. Берәү-бусы син, икәү-монысы син, өчәү-син, дүртәү- ә монысы син. Ә кая соң минем иң яраткан чебешем? Кая соң ул Чеп-чеп?

*Чебешләр.* Чеп-чеп, син кая?

*Чеп-чеп керә. Башында кепка, "Чебешләр" көенә җырлый.*

*Чеп-чеп.* Мин бик шук чебеш, шаян.
Уйнарга көчем табам.
Аякларны яздырам,
Юл буйлап хәйран чабам.
Чеп-чеп, чеп-чеп, чеп-чеп,
Юл буйлап хәйран чабам.

*Чуар тавык.* Чеп-чеп, кадерлем, син кая булдың?

*Чеп-чеп.* Мин ә-нәәә андааа булдым *( ишеккә күрсәтә).*

*Чуар тавык.* Әй, яраткан чебешкәем,
Тыңлаусыз бәләкәчем.
Ярый инде, ярый корт-корт,
Китеп йөрмә бик ерак.
Аланда гына уйнагыз,
Тик берүк адашмагыз.

*Үзәк стенага таба беркетелгән өйгә керә. Чебешләр Чеп-чепне уратып алалар.*

*1нче чебеш:* Чеп-чеп, әйт әле, син кая булдың?

*Чеп-чеп.* Эш буенча йөрдем!

*2 нче чебеш.* Ха-ха-ха, эш буенча ул йөргән!
Юкка кеше көлдергән!

*Чеп-чеп.* Әллә кая йөри диеп,
Сез бит белми көләсез!
Әни алдында, кызганыч,
Ояты миңа беләмсез.

*Чебешләр.* Ни өчен?

*Чеп-чеп.* Бүген мартның сигезе-
Хатын-кызлар бәйрәме.
Иң кадерле кешегә,
Бүләк тиеш түгелме?
Ничек оят түгел сезгә,
Уйламый берегез дә.
Хәзер үк бу мәсьәләне
Хәл итик бергә, бергә.

*3нче чебеш.* Чеп-чеп, безгә бик оят?

*4нче чебеш.* Чеп-чеп, безгә бик кызганыч!

*Чеп-чеп.* Таралышыгыз тизрәк,
Бүләк табарга кирәк!

*Көй астында Чебешләр залның төрле почмакларына таралышалар, һәм алдан әзерләнгән бүләкләрне алып киләләр.Чеп-чеп зал уртасыназур бантлы кәрзин куя. Чебешләр аңа үз бүләкләрен салалар.*

*3нче чебеш.* Әнием, Чуар тавык,
Бераз вакытың табып,
Кил инде син, кил бире,

Бүләгебез күр инде.
*Чуар тавык.* Кыт-кыт-кыт, менә мин дә,
Кем соң дәшеп йөдәтә.
*(Өйдән чыга).Чебешләр бер рәткә тезеләләр.*
*Чебешләр.*Әнием, кадерлем,
Без сине котлыйбыз!
Сиңа озын гомер
Һәм бәхетлек телибез!
*Чуар тавык.* Менә сиңа әкәмәт!
Рәхмәт сезгә, балакайларым!
*Алып баручы кәрзиннән уенчык чыгара.*
Эту славную игрушку подарите маме,
Хороша матрёшка, посмотрите сами!
В ярком сарафане, в расписном платочке,
Вот подарок маме от любимой дочки!
*Песня.*
*Алып баручы кәрзиннән аю чыгара.*
Аюым бакчада тора,
Карурманда туса да,
Уйнарга бик ярата,
Үзе ялкау булса да.
*Җыр.*
*Алып баручы кәрзиннән шылтыравык чыгара.*
Ударяй ладошкой
В бубен посмелей.
Станет всем ребятам
Сразу веселей.
Погремушкам тоже
Хочется играть.
Мы друзей позвали
И давай плясать.
*Песня.*
*Алып баручы кәрзиннән яулык чыгара.*
5.Төрле төстәге яулыклар
Безнең кулларыбызда,
Җилфердәтә – җилфердәтә
Биибез барыбыз да.
*Җыр.*
*Алып баручы:*
Күмәкләшеп без дә, дуслар,
Биеп алыйк, әйдә әле.
- Котлы булсын!
Гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!
*Бию*

*Алып баручы.* Хөрмәтле кунакларыбыз: әниләр, әбиләр! Бүгенге бәйрәмгә килүегез өчен зур рәхмәт сезгә! Сәламәтлек, ак бәхетләр юлдаш булсын сезгә!

**8 нче март бәйрәменә**
**“Леопольд һәм тычканнар”**
**зурлар төркеме өчен бәйрәм сценарие**

Алып баручы: Хәерле көн, безнең иң кадерле кунакларыбыз – әниләр,әбиләр! Сезне барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз. Һәрвакыт шат, сәләмәт, бәхетле булыгыз. Балаларыгызның бүгенге чыгышы сезгә бәйрәм бүләге булсын.

Нигә бүген бөтен җирдә
Чәчәкләр балкый бездә?
Нигә кояш көлеп карый –
Беләбез һәммәбез дә.
Бүген – әниләр бәйрәме,
Бүген җирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.
Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Җирдә барлык балалар.
Мин дә котлыйм, әнкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә!
*ҖЫР.*
Каждый день и каждый час
Думаю о маме.
Мамы тоже любят нас
И гордятся нами.
Каждый день хочу держать
Я в своих ладошках
Руки добрые её,
Ну, хотя б немножко.
Каждый день могу её
Ждать до самой ночи,
Потому что мамы наши
Занятые очень...
Каждый день хочу дарить
Мамочке букеты,
Говорить слова любви,
Как прекрасно это!
Каждый день, не только лишь
День Восьмого марта,
Сделать праздником для мамы
Было бы приятно.
Каждый день бы танцевать,
Удивлять стихами...
Как люблю я мою маму,
Вы поймёте сами.
*ПЕСНЯ.*

Алып баручы: Без бүген сөекле әниләребезгә концерт күрсәтергә уйладык. Ә бәйрәмебезнең алып баручылары бер дә гади түгел, менә хәзер шуны үзегез дә күрерсез. Әнә үзе безнең янга ашыга.

*Звучит музыка из м/ф “Кот Леопольд”. На самокате выезжает Кот Леопольд. Ставит самокат. Выходит на середину. Смотрит на часы.*

Леопольд: Мин вакытында килдем, ахрысы. Исәнмесез, балалар! Исәнмесез, кадерле әниләр һәм балалар. Сезне чын күңелдән 8 нче март халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәм! Бүгенге бәйрәмне үткәрергә мин үземнең ярдәмчеләремне чакырдым. Менә алар үзләре дә килеп керәләр.

*Звучит мелодия песенки “Хвост за хвост” из м/ф “Кот Леопольд”. Появляются мышата. Стреляют из больших рогаток в кота Леопольда.*

Леопольд: Һәрвакыттагыча! Бүген шундый матур бәйрәм, хатын-кызлар көне, ә сез һаман үзегезнең итәсез. Дусларым, әйдәгез тату яшик инде!

Тычканнар: Беркайчанда! Хәтта балалар да үзара дус-тату була белмиләр, нәрсә көтәргә инде бездән-тычканнардан?

*ТАНЕЦ.*

Леопольд: Карагыз инде, балалар ничек булдырдылар, афәрин, әнә бит дуслаштылар. Әйдәгез, без дә тату яшик, бәйрәм хакына булса да...

1нче тычкан: Ярар, шулай да булсын ди, бәйрәм көнне талашып тормабыз инде. Без хәтта сиңа ярдәм итәрбез, Леопольд.

Леопольд: Менә бик яхшы! Ә ничек?

2нче тычкан: Бар, утырып тор, ял ит, ә без балалар белән уйнап алабыз.

*1-ый мышонок усаживает Леопольда на стул, в это время 2-ой мышонок подкладывает воздушный шарик и лопает его. Кот пугается.*

Леопольд: Дусларым, әйдәгез тату яшик инде!

Тычканнар *(смеются):* Без шаярттык! Балалар, чыннан да бик кызык булды, име? Ә хәзер бер уен уйнап алабыз.

1нче тычкан: Ашыкмагыз, дусларым-кечкенә сюрприз!

*Выносят ткань, в которой лежат шары, раскрывают и толкают вверх.*

2нче тычкан: Ура! Бу бит әниләребез, әбиләребез өчен чын салют булды!

Леопольд: Ай-яй! Никадәр чүп-чар. Кем соң моны җыештырыр?

Тычканнар: Ничек инде кем? Без! Шулай бит, балалар?

Леопольд: Туктагыз әле, кемнең инде бәйрәм көнне җыештырып йөрисе килсен?

1нче тычкан: Ә бездә гади җыештыру булмас, без аны бераз үзенчәлекле итәрбез!

Леопольд: Ничек ул алай?

2нче тычкан:

Чүпләрне дә җыярбыз,<br>
Бергәләп без уйнарбыз.

*ИГРА “ВЕСЁЛЫЙ ВЕНИК”. (В игре принимают участие 2 команды – 4 мамы и 4 ребёнка. Между выставленными кеглями нужно провести веником воздушный шарик. Кто быстрее, тот и победитель.)*

Леопольд: Сездән, тычканнар, эш өстенә эш кенә көтәргә була. Карагыз әле үзегезгә, өс киемнәрегезне буяп бетергәнсез бит. Тиз булыгыз, үзегезне тәртипкә китерегез!

1нче тычкан: Ах, син безнең белән ничек кыланасың! Безне бәйрәмнән куып чыгаруыңмы инде бу? Шаярма, Леопольд! Без әле килербез!

Леопольд: Ниһаять, киттеләр. Ә хәзер алар килгәнче, мин концертны дәвам итәм.

*Балалар уртага чыгалар*

Әнием минем матур,
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була
Ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
Әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
Ә куллары йоп-йомшак.
Конфет та кирәк түгел,
Кирәк түгел курчак та,
Чөнки мин әниемне
Алдым инде кочаклап.

*ҖЫР*.

Леопольд: Молодцы! Бүген әниләребез өчен бик күп котлаулар яңгырады, шигырьләр сөйләнде. Ә менә кадерле әбиләребез, дәү әниләребез өчен җырламадык та, биемәдек тә. Ничек болай булсын ди?

Бабушке сюрприз особый мы в честь праздника подарим.
Но не танец и не песню, ещё лучше, интересней!
Раньше бабушка, бывало, сказки на ночь нам читала.
Поменялись мы ролями и расскажем сказку сами.

*КАК ЗАЙЧАТА МАМУ ИСКАЛИ*

*Под музыку вылетают Сорока и Ворона.*

*Сорока:*

Эй, подружка, ты слыхала?
Нынче на рассвете
У зайчихи-бедолаги
Потерялись дети!

*Ворона:*

Дети, говоришь, пропали?
Это же кошмар!
Надо их найти скорее!
Полетели, карр!

*Улетают. Появляются два зайчонка: один побольше ростом, другой — поменьше. Младший зайчонок громко плачет.*

*Первый зайчонок*

Ты, братишка, не реви —
Обойдем весь лес
И отыщем нашу маму,
Если волк не съест.

*Второй зайчонок:*

Как же мы ее найдем?
Лес такой большой!
Здесь мы просто пропадем
Без мамы дорогой.

*Оба плачут. Из дупла выглядывает Белка.*

*Белка:*

Это что тут за потоп?
Мокро все от слез.
Кто же плачет горько так
Здесь, в тени берез?
*Первый зайчонок:*
Это мы, зайчата, плачем —
Потеряли домик свой.
*Второй зайчонок:*
Нам без мамы очень страшно!
Мы хотим домой!
*Выбегает мышка.*
*Мышка:* Ай-яй-яй, беда какая!
Бедные зайчата!
Как же трудно вам без мамы
Здесь в лесу, ребята!
Кто ж вас, бедненьких, накормит,
Кто вас пожалеет?
Кто сырой холодной ночью
Малышей согреет?
*Из берлоги вылезает Медведь.*
*Медведь:*
Что за шум в лесу дремучем?
Что еще за гам?
Кто кричит и громко плачет,
Вспоминая мам?
*Белка:*
Как тебе не стыдно, Мишка,
Малышей ругать!
Взял бы да помог зайчишкам
Маму отыскать.
Сам-то ты в берлоге с мамой
Сытно ешь и пьешь,
Даже в холод лютый самый
Ты в тепле живешь.
*Мышка:*
Как же быть им, невезучим?
Кто научит их
Выжить здесь, в лесу дремучем,
Средь зверей чужих?
*Медведь:*
Да, несладко им придется,
Что лукавить тут!
Если мама не найдется,
Вовсе пропадут.
Мама всех важней на свете,
Всех умней, добрей.
Жить должны все ребятишки
С мамою своей.
*Прилетают Сорока и Ворона.*
*Сорока:*
Эй, вы, звери, не шумите —
Маму мы нашли.

Ворона:
На полянку к трем березкам
Маму привели.
*Выбегает Зайчиха.*
*Зайчиха:*
Мои милые зайчата!
Как я волновалась!
Убежали вы куда-то —
Я так испугалась!
Я боялась, как бы волки
Вас в лесу не съели,
Как бы вы тут не промокли
И не заболели!
*Первый зайчонок:*
Хорошо, что мама наша
Отыскалась и пришла,
Хорошо, что мама наша
Нас в лесу нашла!
*Второй зайчонок:*
Было плохо нам без мамы,
Страшно, одиноко,
Но зато теперь мы с братом
Поняли так много!
*Первый зайчонок:*
Мы не будем больше маму
Огорчать и обижать,
Будем слушаться мы маму,
Будем уважать.
*Второй зайчонок:*
Далеко без разрешенья
Убегать не будем
И расскажем всем, что маму
Очень-очень любим!
*Зайчата обнимают Зайчиху.*
*ПЕСНЯ.*
*Мышата входят в зал. Леопольд сидит и читает газету.*

1нче тычкан: Нәрсә эшли ул?

2нче тычкан: Гәзит укый. Тапкан вакыт, китап яратучы!

1нче тычкан: Ә ул укып утырамыни? Ә аның өчен концертны кем алып барыр? Безме әллә?

2нче тычкан: Хәзер өйрәтәбез аны.

*2-ой мышонок подходит и комкает одной рукой газету.*

Леопольд: Дусларым, әйдәгез тату яшик инде!

1нче тычкан: Әйдә соң! Без бит инде болай да тату. Менә хәзер балаларга бер уен күрсәтәбез. “Гәзитне бөкләп ташла” дип атала.

Леопольд: Нигә дип яхшы гәзитне бозарга?

2нче тычкан: Ул бит синең өчен генә бик яхшы, ә үз вакытларын аш-су бүлмәсендә үткәргән әниләребез өчен бик кызык түгел. Ни өчен дигәндә, бүлмәгә чыгуга әниебезне яхшы гәзит укып утыучы әтиебез каршы ала...Менә шунда башлана инде!

*ИГРА “СКОМКАЙ ГАЗЕТУ” (Играют папы и мамы. Потребуются 2 половника, 2 стула, 2 газеты. Побеждает мама, у которой комок получился меньше.)*

*В зал входят мыши, прячут большую кнопку из картона за спиной.*

1нче тычкан: Леопольд, син, бәлки, концертны алып барып, уеннар уйнап алҗыгансыңдыр, утырып тор, ял ит?

*Леопольд садится на кнопку, лежащую на стуле, подскакивает.*

Леопольд: Дусларым, әйдәгез тату яшик инде!

Мышата: Беркайчанда!

Леопольд: Нишләргә соң миңа сезнең белән?

Алып баручы: Син, Леопольд, бигрәк яхшы күңелле. Сиңа бераз гына “явызлык” даруы эчеп куярга кирәк.

*Ведущая дает Леопольду аскорбинку. Кот принимает таблетку, звереет и выгоняет мышей из зала.*

Алып баручы: Ә хәзер, Леопольд тынычлан. Тычканнар бик ерак качтылар, бәлки инде кайтмаслардыр да.

Леопольд: Алар мине үзләренең шаянлыклары, шуклыклары белән шулкадәр арыттылар.

Алып баручы: Безнең дә балалар кайчагында шаярырга яраталар. Ә син ничек уйлыйсың, безнең әниләребез үз балаларын йомык күзләр белән танырлар микән?

Леопольд: Хәзер беләбез инде.

*ИГРА “УЗНАЙ СВОЕГО РЕБЕНКА” (Мамам завязывают глаза, дети в кругу, нужно на ощупь узнать своего.)*

Алып баручы: Дөресен генә әйткәндә, әниләребез үз балаларын танымаслар дип шикләнмәгән дә идем, чөнки алар үз балаларын бик-бик яраталар. Шуңа күрә дә, үзебезнең язгы концертыбызны тәмамлар алдыннан, әйдәгез, җир йөзендәге барлык әниләр өчен шигырь сөйләп, җыр җырлап үтик.

Бүген җил дә йомшак исә,
Кояш та назлы көлә.
Бүген җиргә иң-иң якты,
Кадерле бәйрәм килә.
Чәчәкләрдән җем-җем итеп
Якты нурлар бөркелә.
Бүгем минем дә әнкәмә
Рәхмәт әйтәсем килә.
Миңа гомер биргән өчен,
Кадерләп үстергән өчен,
Назлы карашлары өчен,
Пешергән ашлары өчен,
Йөрәк җылылары өчен,
Шәфкәтьле куллары өчен,
Барсы, барсы, барсы өчен
Рәхмәт сиңа, сөенечем.
Котлы булсын бәйрәмнәрең,
Рәхмәт сиңа, бөек Кешем!

*ҖЫР.*

Алып баручы:Кумәкләшеп без дә, дуслар,
Биеп алыйк, әйдә әле.
- Котлы булсын!
Гөрләп торсын

Әниләрнең бәйрәме!

*БИЮ.*

*Входят мышата, вносят большую "конфету" и большой букет цветов и просят прощения у Леопольда. Кот прощает мышат, разворачивает "конфету", в ней - конфетки, которыми Леопольд угощает детей. А мышата дарят цветы мамам, бабушкам и воспитателям.*

Алып баручы. Хөрмәтле кунакларыбыз: әниләр, әбиләр! Бүгенге бәйрәмгә килүегез өчен зур рәхмәт сезгә! Сәламәтлек, ак бәхетләр юлдаш булсын сезгә!

**Нәүрүз бәйрәме**

***(Мәктәпкә хәзерлек төркемендәге балалар өчен театральләштерелгән сценарий*)**

Максат:

- Үз халкыбызның тарихы, гореф-гадәтләре, сәнгате аша балаларда милли аң формалаштыру;

-Туган телебезгә, мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

-Эмоциональ сөйләм күнекмәләрен ныгыту;

-Халык музыка коралы булган гармунга, милли көйләребезгә, уеннарыбызга кызыксыну уяту;

Алдан күрелгән чара:

Балалар белән: Яз бәйрәменә багышланган шөгыльләр, әңгәмәләр, татар халык уеннары уйнау: “Ал кирәк, гөл кирәк”, “Читәнле”, “Буш урын” һ. б.

-татар халкының бай мирасы белән таныштыру, уеннарын, җырларын өйрәтү;

-бәйрәмгә шигырьләр ятлау, сөйләм телен ныгыту;

-бию алымнарын күрсәтү, татар халкының биюенә хас үзенчәлекләр турында сөйләү.

Әти-әниләр белән: Нәүрүз бәйрәме турында сөйләү;

-бәйрәмгә балалар өчен костюмнар әзерләүдә ярдәм сорау.

Җиһазлау:

1. Фортепиано, музыкаль үзәк, аудио язмалар.

2.Катнашучыларга бәйрәм костюмнары.

3. 1 балада гармун, берничәсенә чиләкләр .

4.Сыйлау өчен халкыбызның яраткан ризыгы-кош теле.

5. Бию өчен- умырзая чәчәкләре.

Бәйрәмчә бизәлгән зал:

1.Чиккән сөлгеләр;

2. Бер читтә читәнле өй, анда әтәч утыра, читәнгә чиләк-көянтә эленгән;

3.Чәчәкләр.

Катнашалар: Алып баручы, әби, бабай, балалар, Нәүрүз.

*Нәүрүз бәйрәменең барышы:*

*Алып баручы*. Исәнмесез, саумысыз, һәр барчагыз! Бүген бездә бәйрәм көн! Бүген бездә Нәүрүз бәйрәме! Кыш үтеп көн белән төн тигезләшкәндә бәйрәм итәләр Нәүрүзне. Ул ике атанага сузыла. Бу көнне егетләр һәм кызлар өйдән-өйгә кереп, хуҗаларга такмаклар әйткәннәр, аларны бәйрәм белән котлаганнар.

Ә хәзер без сезгә Нәүрүз бәйрәме көннәрендәге күренешләрне тәкъдим итәбез, рәхим итеп карагыз!

*Өй эчендә әби белән бабай. Шул вакыт гармун тавышы ишетелә. Бу тавышка әби белән бабай чыга. Өй тирәли балалар җыела. Нәүрүз әйтәләр.*

Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез.
Аш-сый күтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәк булсын.

*Балалар.* Исәнмесез, хуҗалар!

*Әби.* Исәнмесез, әйдәгез, түрдән узыгыз!

*Беренче бала.* Нәүрүз котлы булсын!
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын.
Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез бик уңсын,
Күңелләрегез булсын.

*Әби.* Яхшы теләкләрегез өчен рәхмәт, балакайлар.

*Икенче бала(бабай янына килеп).*
И, Иш бабай, Иш бабай,
Мич башыннан төш, бабай.
Капчык авызын чиш, бабай.
Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң ярар ике алтын.

*Өченче бала.* Нәүрүз мөбарәк булсын!
Бабай, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

*Дүртенче бала.* Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый көтеп торабыз.
Бардыр сезнең маегыз,
Яки бардыр балыгыз,
Барын безгә куегыз,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

*Әби.* Бар-бар. Менә сезгә бал, менә сезгә май.

*Алып баручы.* Күчтәнәчләрегез өчен зур рәхмәт сезгә, әби. Безнең балаларыбыз бүген Нәүрүз бәйрәменә җыелдылар. Менә сез дә үз чорыгызның җырлары, биюләре белән бүлешсәгез иде.

*Әби.* Әйдәгез, сый-хөрмәтне куеп торабыз да, яшь вакытларны искә алып, күңел ачабыз.

*"Шома бас" көенә җырлы-бию башкарыла.*

*Алып баручы.* Әби белән бабайның җырларын искә төшердек, инде безнең балаларыбыз да биеп күрсәтсеннәр.

*Балалар башкаруында Татар халык биюе.*

*Алып баручы.* Рәхмәт сезгә, балалар. Бик матур биедегез. Әби белән бабайны да яшәртеп җибәрдегез.

*Бабай.* Шулай, балалар. Шуның өчен чәй белән сыйлык әле үзегезне. Әйдә, карчык, өстәл әзерләрсең.

*Әби.* Күңел ачып онытылып та киткәнмен. Әзерлибез, атасы, әзерлибез. Ә сез балалар бәйрәмегезне дәвам итегез.

*Әби белән бабай чәй әзерләргә кереп китә. Балалар урындыкларга утырышалар.*

*Алып баручы.* Балалар, Нәүрүз бәйрәмен кыр-яланнарда, су буйларында, тау итәкләрендә үткәрә торган булалар. Иртән урамда учак кабызып, итле шулпа пешергәннәр. Хәлле кешеләр кышны авыр чыккан дусларын, туганнарын сыйлаганнар. Озын кышны чыгу кешеләргә җиңел булмаган. Алар тизрәк Нәүрүз бәйрәменең килүен көткәннәр. Шуңа күрә ул шатлыклы яз бәйрәме-өмет бәйрәме дип билгеләп үтелгән.

Әйдәгез, балалар, без дә бүгенге кунагыбыз Нәүрүзбикә килгәнче, биеп күңел ачыйк әле.

*Беренче бала.* Нәүрүз юлга чыккан бит,
Умырзая шыткан бит.
*Балалар.* Әйе, әйе, умырзаялар шыткан,
Яз җиткән, яз җиткән!

*Кызлар тарафыннан "Умырзаялар" биюе башкарыла.*

*Алып баручы.* Хәтерлисезме, балалар, 20 нче март көнне яз хәбәрчеләре-кара каргалар килде. Алар яз киләсен хәбәр итте.

*Залга музыка астында кара каргалар булып киенгән 3 бала керә.*

*Беренче карга.* Ачылды ак калын юрган,
Исә язгы җилләр дә.
Без кайтабыз сагындырып,
Туып үскән илләргә.
*Икенче карга.* Көннәрне юлда үткәреп,
Куанышып сезгә очтык.
Канат очларына элеп,
Сезгә яз алып кайттык.
*Өченче карга.* Яз кызы Нәүрүзбикә сезгә тиздән килеп җитә.

*"Кара каргалар" очып чыгып китәләр.*

*Алып баручы.* Рәхмәт сезгә, кара каргалар-яхшы хәбәрегез өчен. Аны без шундый зарыгып көтәбез. Быел бигрәк соңарып йөри. Мөгаен, барасы юллары бик ерактыр. Аны бит татар халкы, гомумән, төрки халыклар яшәгән җирләрдә теләп көтеп торалар.Безнең балалар матур шигырьләрен сөйләми торып, Нәүрүзбикә килмәс, ахрысы.

*Балалар шигырь сөйлиләр.*

*Беренче бала.* Көннәр аяз, күктән алсу,
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы,
Сагынып көткән яз килә.
*Икенче бала.* Әйтегезче, кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк!

*Көчле музыка астында залга биеп Нәүрүзбикә керә.*

*Нәүрүз.* Исәнмесез, балалар, исәнмесез, кунаклар! Бәйрәм белән сезне!

*Алып баручы.* Хуш киләсең, Нәүрүз, хуш киләсең,
Кышлар буе көттек үзеңне.
Балаларга ач син йөзеңне,
Һәм ирештер татлы сүзеңне.
*Нәүрүз.* Мин үзем дә сезне сагынып килдем,
Теләкләрем ихлас күңелдән.

Юлыгызга якты бәхет юрап,
Яз гөлләре булып сибелгән.

*Алып баручы*. Рәхмәт, Нәүрүз изге теләгеңә,
Алар чынга аша күрсеннәр.
Бу балалар бәйрәм көннәрендә
Шулай уйнап, җырлап йөрсеннәр.

*Нәүрүз*. Кызлар, егетләр! Мин сезгә электән калган бер бик матур уен алып килдем. Ул уен -“Буш урын” дип атала.

Егетләр һәм кызлар кулны кулга тотынышып түгәрәк буйлап җырлап әйләнәләр:

Саескандай титаклап,
Мин йөримен өй саклап.
Каздай булып кыйкаклап,
Сиңа тиям син әбәк.

Түгәрәктән читтә әйләнүче бала җыр туктауга, берәрсенә барып төртә. Ике арада урын өчен ярыш башлана. Кем беренче түгәрәккә кереп баса-шул җиңүче. Уен берничә тапкыр кабатлана.

*Нәүрүз*. Рәхмәт, балалар. Икенче юлы мин сезгә тагы бик кызыклы уеннар алып килермен.Беләсезме, мине башка өлкәләрдә дә бик теләп көтәләр. Шуңа да миңа бик ашыгырга кирәк. Язларыбыз имин, кешеләребез иманлы, җиребез тыныч булсын! Сау булыгыз!

*Балалар*. Хуш, Нәүрүзбикә.

*Алып баручы*. Рәхмәт сиңа, Нәүрүзбикә. Хәерле юллар сиңа. Без дә синең теләкләреңә кушылабыз: күгебезгә яктылык, җаныбызга изгелек, көнебезгә игелек, тормышыбызга ныклык, тамагыбызга туклык булсын. Шулаймы, балалар.

*Балалар.Шулай.*

*Тәм-том әзерләп, әби белән бабай чыга.*

*Әби*.Менә кучтәнәчләребез дә әзер. Сыйланыгыз, балалар. Безнең күңелне күреп, яз бәйрәме белән котлавыгыз өчен рәхмәт. Бәхетле балачак сезгә.

*Алып баручы*.Нинди өлгерләр дә үзегез. Шул арада никадәр сый әзерләгәнсез. Әнә яшәреп тә киттегез. Әлбәттә, безнең халкыбыз җыр-моңнарсыз яши алмый. Бәйрәмнәребез бүгенге көнгә кадәр сакланган. Ә без балалар, татар халкының мирасчылары буларак уеннарыбызны, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны өйрәнергә, онытмаска тиешбез. Тырышырбызмы?

*Балалар*.Тырышырбыз. Без-татар булуыбыз белән горурланабыз! Үз телебезне саклабыз!

*Алып баручы*. Яңә яз яшелләнә.
Җир-анабыз гөлләнә.
Бозны тишә ак чәчәк,
Көнгә бага саф чәчәк!
Бүген көн тиң төннәргә,
Урын юк һич көнләргә,
Нәүрүз мөбарәк булсын!
Нәүрүз мөбарәк  булсын!

**“Яз бәйрәме”**

Максат: Язның бер көне ел туйдыра!-мәкаленең асылын аңлату.

*А.Б.:* Бүген бездә бәйрәм – күңелле Яз бәйрәме. Күрәсезме, зал ничек бизәлгән? Төрле төстәге чәчәкләр. Кошлар сайрый. Бүген Яз үзе дә безгә кунакка килә.

Йә, балалар, карагыз,
Тышта, әнә, килә яз.

*БАЛАЛАР:*

Әйе, әйе, күрәбез,
Яз килгәнен беләбез.

*А.Б.:* Миңа якын килегез
Яз турында сөйләгез.

*1.* Канат кагып ерактан
Кошлар кайтты көньяктан. *(балалар очу хәрәкәтләре ясыйлар)*

*2.* Тамчы тама тып та, тып,
Булмый аны туктатып. *(учларына бармак белән төртеп күрсәтәләр)*

*3.* Зәңгәр күктә кояш балкый,
“Тышка чык” дип безне алдый. *(кулларын югары күтәре күккә күрсәтәләр)*

*4.* Сикергеч туп кулга алыйк,
Сикереп уйнап карыйк. *(туп сикерткән хәрәкәтләр ясыйлар)*

*5.* Яз бездә озак тормый
Җәй килер җырлый-җырлый. *(кулларын чабып, бер урында сикерәләр)*

*1.* Җылы җил сирпеп үтте
Агачларны селкетте:
- Уяныгыз, уян тизрәк,
Яз җитте,
Әй, яз җитте!*(Бергә.)*

*2.* Кояш нурларын сипте,
Тәрәз битләрен үпте:
Ачылыгыз, ачыл тизрәк,
Яз җитте, Әй, яз җитте!*(Бергә.*

*3* .Сыерчык сайрап үтте,
Һавалар зыңлап китте:
Чыгыгыз, чык, әй, балалар,
Яз җитте, Әй, яз җитте!*(Бергә.)*

*4* .Яңгыр сибәләп үтте,
Кырлар яшәреп китте.
Нурга тулды туган җирләр,
Яз җитте,
Әй, яз җитте!*(Бергә.)*

*Җыр.*

К нам весна шагает
Быстрыми шагами,
И сугробы тают
Под её ногами.
Чёрные проталины
На полях видны.
Верно, очень тёплые
Ноги у весны.

*Песня.*

Весна идёт! Весна поёт!
И с ней ликует весь народ.
С зимой ушли печаль, ненастье,
Весна приносит только счастье!

*Гимнастическая композиция.*

*Әби*. Менә озакламый күптән көттергән Яз чибәркәй килеп җитәр. Ул килгәнче, күмәч пешерергә кирәк. Әнә камыр да күтәрелеп килә. Ой, ә бу нәрсә? (*Бер йомры икмәк сикереп чыга*). Бу хикмәтле икмәк миңа нидер әйтергә тели, ахрысы. Кая соң әле минем тылсымлы яулыгым? *(Күмәчне яулык белән каплый да,кулларын болгый башлый)*.

Әфсен-төфсен, бер-ике-өч!

Әфсен-төфсен, терелсен!

*Йомры күмәч телгә килә.*

*Йомры күмәч.* Исәнме, әби! Син кунакка Язны көтәсеңме? Бик яхшы, бик күңелле бәйрәм булыр! Ә мин аның каршысына йөгерим, тизрәк бәйрәмгә ашыктырыйм.

*Әби*. Ашыкма, йомры күмәч, көтеп тор. Синең бит бер як кырыең алланып та бетмәгән, әйдә, мин сине тәрәз төбенә кояшка куйыйм.

*Йомры күмәч (тәрәзә төбендә утыра, җырлый):*

Мин - күмәч, йомры күмәч,
Минем йөзем гел көләч.
Кояш мине ярата,
Битләремне аллата.
Сукмак буйлап йөгерәм,
Тизрәк Яз килсен диям.
Җыелырбыз без бергә –
Җырларга һәм биергә.

*Алып баручы (балаларга эндәшә)*.Әйдәгез, балалар, бездә сезнең белән йомры күмәчкә иярик, бергәләп Язны каршы алыйк. Карагыз, ул инде-юлда, ә каршысына бер куян килеп чыкты.

*Куян.* Күмәч, йомры күмәч, мин сине ашыйм!

*Йомры күмәч.* Син мине ашама, кылый куян, мин сиңа җыр җырлыйм. Тыңла!*(Җырлый.)*

Мин – күмәч, йомры күмәч,
Минем йөзем гел көләч!
Кояш мине ярата,
Битләремне аллата.
Сукмак буйлап йөгерәм,
Тизрәк Яз килсен диям.
Җыелырбыз без бергә-
Җырларга һәм биергә.

*Куян.*Бик яхшы җырлыйсың. Мин әйткән табышмакны чишә алсаң - җибәрәм.

*Йомры күмәч.* Балалар, ә сез миңа ярдәм итәрсезме?

*Балалар.* Әйе.*(Табышмак.)*

*Куян.* Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?
Йә, әйтеп кара.

*Балалар.* Яз!!!

*Куян.* Дөрес! Ярый, мин сине, Йомры күмәч, тоткарламыйм, юлыңда бул! Язга миннән сәлам әйт!

*Алып баручы.* Йомры күмәч тәгәри-тәгәри бара икән, каршысына бүре килеп чыккан.

*Бүре.*Исәнме, Йомры күмәч! Без синең белән бик вакытлы күрештек! Мин шундый ач...

*Йомры күмәч.* Син мине ашама, соры бүре, мин сиңа җыр җырлыйм. Тыңла!*(Җырлый.)*

Мин – күмәч, йомры күмәч,
Минем йөзем гел көләч!
Кояш мине ярата,
Битләремне аллата.
Сукмак буйлап йөгерәм,
Тизрәк Яз килсен диям.
Җыелырбыз без бергә-
Җырларга һәм биергә.

*Бүре.* Бик яхшы җырлыйсың. Яз турында шигырь сөйли алсаң – җибәрәм.

*Йомры күмәч.* Балалар, миңа ярдәм итәрсезме?

*Балалар.* Әйе. *(Шигырь.)*

Гөрләвек ага,
Кояш елмая,
Торналар үтте
Төзелеп бая.
2. Гөрләвекләрдә
Уйный үрдәк, каз,
Илне яшәртеп,
Шаулап килә яз.

*Бүре.* Бик яхшы, Йомры күмәч, мин сине җибәрәм, ераккарак тәгәрә! Язга миннән сәлам әйт!

*Алып баручы.* Йомры күмәч тәгәри-тәгәри бара икән, каршысына аю килеп чыккан.

*Аю.* Күмәч, йомры күмәч, мин сине ашыйм!

*Йомры күмәч.* Син мине ашама, кыйшык аяк, мин сиңа җыр җырлыйм. Тыңла!*(Җырлый.)* Мин – күмәч, йомры күмәч,
Минем йөзем гел көләч!
Кояш мине ярата,Битләремне аллата.
Сукмак буйлап йөгерәм,
Тизрәк Яз килсен диям.
Җыелырбыз без бергә-
Җырларга һәм биергә.

*Аю.*Барыбер ашыйм.(*Йомры күмәч моңсулана, авыр сулый.)*Ярый, борчылма, мин бүген яхшы күңелле. Яз турында җырласаң – җибәрәм.

*Йомры күмәч.* Балалар, миңа ярдәм итәрсезме?

*Балалар.* Әйе! *(Җыр.)*

*Аю(шаккатып).*Бик шәп, мин сине җибәрәм. Язга карт аюдан сәлам әйт.

*Алып баручы.* Аю үз юлы белән, ә йомры күмәч үз юлы белән китте. Йомры күмәч тәгәри-тәгәри бара икән, каршысына Төлке килеп чыккан.

*Төлке.* Исәнме, йомры күмәч, син нинди гүзәлсең?! Кара әле, үзе минем каршыма йөгереп чыкты! Ашыйм...

*Йомры күмәч.*Нәрсә соң бу бүген? Тынычлап кына Язны каршыларга бирмиләр!

Төлке, син шундый акыллы һәм хәйләкәр, бик күп хикмәтләр беләсең!

Әйдә болай итәбез: мин балалар белән сиңа бер матур уен күрсәтәм, ә син мине җибәрәсен Язны каршыларга. Килештекме?

*Төлке.* Ярый!

*Йомры күмәч.*Балалар, миңа ярдәм итәрсезме?

*Балалар.* Әйе! *(Уен.)*

*Төлке.* Эх, мин тагы ач калдым.Әмма мин үз сүземә каршы килмим. Сиңа тимим. Язга миннән сәлам диярсең!

*Йомры күмәч(балаларга эндәшеп).*Балалар бик зур рәхмәт сезгә, миңа бик нык булыштыгыз. Ә хәзер бергәләп Язны кунакка чакырыйк.

*Бер бала.* Яз, яз, кил инде,
Бер елмаеп көл инде.
Карлар тизрәк эресен,
Гөрләвекләр йөгерсен,
Җырчы кошлар кайтсын,
Кырда үлән калыксын.
Елга боздан арчылсын,
Зәңгәр күкләр ачылсын,
Кояш йөрсен күк тулып,
Алтын шар кебек булып.
Йә инде, яз, кил инде!

*Барысы бергә.*Яз-чибәркәй! Яз-чибәркәй!

*Ерактан кошлар сайраган тавыш ишетелә. Үзенең чәчәкләре белән Яз чибәркәй килеп керә.*

*Чәчәкләр бию.*

*ЯЗ:* Исәнмесез, нәни дусларым! Сез мине таныдыгызмы? Әйе, мин Яз.

*А.Б.:* Исәнме, Яз! Хуш килдең, әйдә! Сине күптән без сагынып көтәбез.

*ЯЗ:* Яз бәйрәме белән, дуслар,
Тәбриклим сезне.
Күп шатлыклар алып килсен
Бу Яз бәйрәме!

Вот и всё! Дождались!
Вот она, весна!
А уж нам казалось,
Не придёт она.

2. Долгий путь прощла весна,
Чтобы вновь придти.
Осень, долгая зима
Встретились в пути.

3. Но назло невзгодам,
Будто в чудном сне,
Ожила природа.
Так привет весне!

*Песня.*

Всё весною расцветает,
И танцует, и играет.
Вот танцует ручеёк,
Пляшет первый лепесток,
В танце кружатся капели,

Успевая еле-еле.
Как же детям устоять?
Тоже надо танцевать!
*Танец.*
Менә инде яз килде,
*(кулларын алга сузып күрсәтәләр)*
Түбәдән тамчы тама,
*(бармак очлары белән үч төпләренә чиртәләр)*
Көндез көн җылы була,
*(кулларын чайкыйлар)*
Суыта кичкә таба.
*(чүгәлиләр)*
3.Тамчылар бии тып та тып,
*(балалар кулларында бармак очларын "биетәләр")*
Тамчылар сикерәләр,
*(урыннарында сикерәләр)*
Аларны булмый туктатып,
Алар яз китерәләр.
*(кул чабып, бииләр)*
*Җыр.*
*А.Б:* Күмәкләшеп без дә, дуслар,
Биеп алыйк, әйдә әле.
Котлы булсын!
Гөрләп торсын
Безнең Яз бәйрәме!
*Бию.*
*А.Б.:* Яз бәйрәме дә тәмам. Җылы һәм шатлык алып килгәнен өчен сиңа, Яз, зур рәхмәт.